www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 2 (1418) 20 гыйнвар 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga


2

Балык Бистәсенең Балтач авылы мәктәбендә Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның бай эчтәлекле, заманча музее ачылды.

12

Актаныш районында дөньяга килгән Әсгать Сафаргалин сәнгать үрләрен ерак Харьков каласында яулый.

14

Кытайда туып-үсеп тә, татарлыктан аерылмыйча яшәргә, татар телен камил белергә була дип раслый чин иле татары Нәгыйулла Хәсәнов.

Кайнар өммәттәшләр алышканда, Кайнарланып китә бозлар да!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан үзәгендә реставрацияләнә торган мәдәни мирас объектларыннан 1837 елда төзелгән «Дротоевский йорты», 1908 елда төзелгән «Чукашев йорты» һәм Казан сәнгать училищесы бинасындагы эшләр белән танышты.

- Башкортстанның беренче Президенты Мортаза Рәхимов 88 яшендә вафат булды.

- К.Тинчурин театрында 26-27 гыйнварда «Идегәй» татар халык дастаны буенча әзерләнгән спектакльнең премьерасы була.

- Татар китабы йорты 14 яшьтән 30 яшькә кадәр иҗатчылар өчен дүрт айлык Әдәби мәктәп ача.

- Башкортстанның Милли симфоник оркестры Татарстанга чираттагы гастрольләре вакытында Сайдашев исемендәге Дәүләт зур концертлар залында, Чаллының Орган залында, Түбән Каманың Сайдашев исемендәге музыка көллиятендә концерт бирәчәк.

- Фаил Шәфигуллинның дүрт томлык «Сайланма әсәрләр»енең юмор-сатира әсәрләре тупланган беренче томы дөнья күрде.

- Мәскәүдәге Хәзерге заман тарихы дәүләт музеенда «Ислам бакчалары. Гасырлар аша иман нуры» күргәзмәсе эше төгәлләнүгә багышланган тантанада Россиядәге беренче басма (1787 елда нәшер ителгән) Коръәннең төп нөсхәсе күрсәтелде.

- Әтнә районының Яңа Шашы авылында яңа мәчет ачылды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ, әдәбият галиме:

«Әдәби әсәрләрнең интернет челтәре аша укучыларга тиз арада килеп ирешүе, социаль челтәрләрдә әдәби тәнкыйтьнең «фикер алышу» формасын, ягъни «җанлы тәнкыйть»не активлаштырды. Бу күренеш әсәр турында кыска гына фикер әйтеп, аны киң җәмәгатьчелеккә таныту мөмкинлеге бирә. Әмма куркыныч ягы шунда: һәркем үзенең язганнарын урнаштырып, шактый йомшак әсәрләрне дәлилсез мактауга, иҗат үрнәге буларак таратуга китерә, аерым очракларда исә алар турында шактый беркатлы бәяләмәләр дә урын ала».

СЫНАМЫШЛАР

20 гыйнварда җылы булса, кырда ашлык куе булыр; ябалак кар яуса, иген бик уңар ● Егермесендә көн салкын – уракта сугар ялкын ● Егермесендә бик салкын булса, урак вакытында бик эссе булыр; җылы булып, кар яуса – һәртөрле ашлык уңар; ябалак кар яуса – борчак белән чикләвек уңар ● 24 гыйнварда агачларны бәс сарса, җәй яңгырлы килер ● Гыйнвар җылы булса, яз соң килә ● Гыйнварда аяз һәм суык булса, эссе, коры җәй фаразлана.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 59 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 51 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **7 сәгать 52 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **25 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **27 гыйнварда 8 сәгать 17 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

20 гыйнвар – баянчы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рокыя Габдрахман кызы Ибраһимованың тууына 110 ел (1913–1998).

21 гыйнвар – шагыйрь Әгъзам Камалетдин улы Камалетдиновның тууына 105 ел (1918–1943).

25 гыйнвар – актриса, Татарстанның һәм Русия Федерациясенең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Нәҗибә Гыймай кызы Ихсанованың тууына 85 ел (1938–2021);

– җырчы, Татарстанның атказанган артисты Эльмира Рамил кызы Кәлимуллинага 35 яшь (1988).

26 гыйнвар – балалар язучысы Әминә Әхмәт кызы Бикчәнтәеваның тууына 110 ел (1913–1986).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Гыйнварның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үзүзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 20 гыйнвар.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(21-28 гыйнвар)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген җомәдел ахир аеның 28 нче көне

МУЗЕЙХАНӘ

Вахит ИМАМОВ

ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ МУЗЕЕ

Яңа елның беренче эш атнасы ук шигърият сөючеләрне яңа бүләк белән сөендерде – Балык Бистәсе районының Балтач авылында Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин тормышына һәм иҗатына багышланган музей ачылды.

12 гыйнвар иртәсендә халык шагыйре туып-үскән Балтач авылына машиналар ташкындай агылды, дисәк тә зур арттыру булмас. «Татмедиа» җәмгыятендәге һәр редакция коллективы – үз вәкилен, Татарстан Язучылар берлеге – Равил ага каләмдәшләрен, Балык Бистәсе районындагы 20 мәктәпнең һәркайсы – директорларын һәм татар теле һәм әдәбияты мөгаллимнәрен юллауны үз бурычы дип санаган. Өстәвенә, шушы ук район халкыбызга һәрбер тамашачы өчен сөекле булган Равил ага Шәрәфиевне, хезмәтләре белән милләт алдында танылган Нурулла Гариф кебек тарихчыны, Рахман Шәфигуллин кебек прозаик һәм журналисты, Рәсимә Гарифуллина һәм Вазыйх Фатыйхов кебек шагыйрьләрне дә бүләк иткән бит, алар да халык шагыйре Равил Фәйзуллин бәйрәменнән читтә кала алмаган. Тагын саный китсәң, районда үз заманнарында колхоз-совхозда эшләгән һәм Равил ага белән аралашып, дуслар булып яшәгән якташлары да санап бетергесез, алар да шагыйрь бәйрәменә рәхим иткән. Араны ерак дип тормаган, Равил аганы якын дусты иткәч, Түбән Кама каласында инде 30 ел элек үк татар драма театрын нигезләүче һәм бүгенге көнгәчә гөрләтеп яшәтүче режиссерыбыз Рөстәм Галиев та килеп җиткән.

Авылга керүгә үк игътибар итми кала алмадык: монда урамнар исеме дә гел шигърият бакчасындагы кебек – Татарстан урамы, Габдулла Тукай һәм Һади Такташ урамнары, әлбәттә, Равил ага исемендәгесе дә бар. Шагыйрьнең музее да 2003 елдан бирле аның исемен йөртүче мәктәп бинасында урнашкан булып чыкты. Килеп җиткәч тә, әйе башкалар өлгергәнче дип, аңа күз йөгертеп чыгарга ашкындык. Шагыйрьнең бала чагын чагылдырудан башланган фотогалерея, 40 тан артык китабы, хөрмәтле каләм ияләренең Равил ага турында әйткән сүз һәм бәяләре, шәхси ядкәрләре, бүләкләр, истәлекләр. Аерым бер пыяла стенд астына Равил аганың әле 11 яшьлек малай чагында ук яза башлаган көндәлек битләрен һәм тәүге шигырь өйрәнмәләрен дә урнаштырганнар. Башка әдәби музейларда моңа тиң ядкәрләр бик күренми, шул ягы белән Равил ага мирасханәсе үзгәрәктер.

Аннары Равил аганың музей диварларында меңәрләгән кешеләр өчен кадерле булып калган Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Вафирә Гыйззәтуллина, Әмирхан Еники, Туфан Миңнуллин белән бергә төшкән фотосурәтләрен күзәтү дә җылы сүзгә сусаган бүгенгедәй кырыс заманада якты хатирә кояшчыгы булып ялтырый.

(Дәвамы 4 нче биттә).



Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

«Монафикълык ярминкәсе»

Россиянең БМОдагы даими вәкиле Василий Небензя, Куркынычсызлык Шурасының (КШ) 13 гыйнварда Украина буенча үткән утырышында ул утырышларны, Бөекбритания язучысы Уильям Теккерейның «Мин-минлек ярминкәсе» дигән романына ишарәләп (һәм башкаларны да үзенә тиңләп булса кирәк), «монафикълык ярминкәсе» дип атаган. Әлбәттә, шәхсән аның күзлегеннән караганда, бәлки, ул шулайдыр да. Әмма монының өчен алдан рухи кыйммәтләр деградациясе дә кичерергә (ягъни, шартлыча, акны – кара, яманны исә яхшы дип тә танырга) кирәктер. Аңлашыла ки, аңа карап кына чынбарлык үзгәрми һәм ул әйткәннәр дә, асылда, буш сүз тезмәсе генә булып чыга. Чөнки абсолют кыйммәтләр системасында ак-ак булып, яман исә яман булып кала. Икенче яктан, даими вәкилнең үзе дә утырышларында катнашкан халыкара орган әшенә мондый бәя бирүе үзе үк тә икейөзлелек күрсәткече була түгелме? Шул ук вакытта (һәм иң гаҗәпләндергәне дә шул!) ул ошбу органнан инде үзе дә Россияне борчыган мәсьәлә буенча якын көннәрдә БМО КШ утырышын үткәрүен сораган.

13 гыйнварда үткән утырышта Киев үз иминлеген тәэмин итүнең күп кенә аспектларын күтәргән. Украина тышкы эшләр министрының беренче урынбасары Әминә Җапарова (ә ул үзе – Кырым татары икән) БМО илләрен шулай ук В.Зеленский тәкъдим иткән «тынычлык формуласы»н якларга да чакырган һәм аның буенча «тынычлык саммиты» инде, БМО ГА ның гадәттән тыш махсус сессиясе рәвешендә, 24 февральгә кадәр дә үтәргә мөмкин, дип саный. Анда шулай ук Россиянең Украинадагы гамәлләрен тикшерү өчен халыкара платформа булдыру турында резолюция проекты да каралырга мөмкин икән.

БМО генераль секретаренең сәяси мәсьәләләр буенча урынбасары Розмари ДиКарло исә әлеге утырышта ясаган чыгышында: «Украина, Россия һәм дөнья мондый хәлнең дәвам итүенә юл куя алмый. Генераль секретарь анда катнашучы якларга ошбу мәгънәсез вә аклап булмый торган конфликтны БМО уставы һәм халыкара хокук нормалары нигезендә тәмамлауга ярдәм итәргә әзер», – дип белдергән. Аның БМО мәгълүматларына таянып әйтүенчә, Украинада гади халык арасында үлүче вә яралanучыларның рәсми саны инде 18096 кешегә җиткән. Ә ул реаль саннарның күпкә артык булуын да яшерми. Розмари ДиКарло шулай ук бу илдән 7,9 миллион чамасы качакның Европада яклау эзләвен, тагын 5,91 миллион тирәсе кеше исә (ә алары арасында 65 проценты – балалар һәм хатын-кызлар икән) эчке күченүчеләр санын арттыруын да әйтә.

Инде БМО КШ утырышында әйтелгән кайбер фикер вә карашларның югарыда телгә алынган «монафикълык ярминкәсе»ндә ничек бәяләнүенә дә күчик. Тәрҗемә төгәлсезлеге килеп чыкмасын өчен, В.Небензя бәяләмәләрен оригиналында, тәрҗемәсез генә китерербез. Киев тәкъдим иткән «тынычлык саммиты»н ул «пропагандистская пустышка» дип атаган һәм аны, «за этой красивой оберткой скрывается весьма гнилая инициатива и даже двойное дно. В Киеве не скрывают, что мир по-украински – это капитуляция России, которую должно зафиксировать международное сообщество», дип бәяләгән. Әлеге инициативаның максатын ул Киевнең Көнбатыш җәмәгатьчелегенә ярарга тырышуы белән (имеш, Украинага бүленгән акчаның кая китүе турында уңайсыз сораулар бирмәсен өчен) аңлаткан. Монда инде, көлсәң – көл, көлмәсәң – ела, дияргә генә кала. Мантыйк вә фикерләү дәрәҗәсе – искитмәле! Шуңа, ахры, Киевнең махсус трибунал булдыру идеясенә КШ утырышында җавап, «нелепая идея» диюдән артмаган. Аның каравы, соңыннан әлеге бушлыкны даими вәкилнең беренче урынбасары Д.Полянский тутырырмакчы булды. Ул БМО ГАның махсус трибунал төзүгә вәкаләтләре булмавы турында белдерде. Әмма, кайбер белгечләр әйтүенчә, шул ук максатларда ул БМО ГА илләренең глобаль юридик платформасын булдыра ала. Кыскасы, алда әле бу җәһәттән юридик коллизияләр күп булыр кебек. Ә «монафикълык ярминкәсе»нә килгәндә, халыкара абруйлы оешмаларда аңа җирлек калдырмас өчен, вакыйга вә фактларны инде абсолют кыйммәтләр системасында бәяли башларга гына кирәктер.

Фоат УРАЗАЙ.

Саллы хезмәт

Россия ислам институтында «Россиядә ислам тарихы» исемле тиңсез басманың китап туе узды. Ул Идел буе Болгар дәүләте халыклары тарафыннан ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы чаралары кысаларында Татарстан Мәдәният министрлыгы, Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм фонды булышлыгы белән дөнья күрде.

«Россиядә ислам тарихы» – беренче коллектив монография, анда югары фәнни дәрәҗәдә Россия мөселман халыкларының ислам цивилизациясен үстерүгә керткән өлешен илебездә ислам үсешенең барлык этапларын системалы рәвештә бән итү аша төрле яклап анализлау омтылышы тормышка ашырыла. Китапта мөселман берләшмәләренең барлыкка килүе һәм эшчәнлеге, Россия мөселман өммәтенең рухи яңарыш барышын һәм интеллектуаль үсешен анализлау юлы белән хәзерге шартларда ислам дине күтәрелешенең төп тенденцияләре яктыртыла.

РИИ ректоры Рәфикъ Мөхәммәтшин әлеге академик фундаменталь басманың Бөтендөнья мөселман берләшмәләре советы теләктәшлегендә әзерләнүен билгеләп үтте – гарәп галимнәре ислам диненең гарәп дөньясыннан читтә һәм гарәп булмаган халыкларда ничек формалашуы белән кызыксына. Басма 5 бүлектән тора: «Россиядә Исламның таралуы»; «Россия мөселман өммәтенең рухи яңарышы һәм интеллектуаль үсеше проблемасы: тарихи контекст һәм заманчалык»; «Россия мөселманнарында дини оешмаларның барлыкка килүе һәм үсеше»; «Хәзерге Россиядә Ислам», «Ислам һәм рухи мәдәният».

Басманың фәнни мөхәррире сүзләренә караганда, Россиядә ислам тарихы яхшы өйрәнелгән – Идел буе Болгар дәүләтендә, Алтын Урдада һ.б. ислам тарихын яктырткан хезмәтләр бар. Әмма зур галимнәр тарафыннан язылган бербөтен басмалар юк иде.

Китап Россия ислам институтында рус, инглиз һәм гарәп телләрендә әзерләнгән. Аны язуда кулланган чыганак һәм әдәбият файдаланылган (алар 1000 нән артык), ислам тарихы өлкәсендә әйдәп баручы Россия белгечләре җәлеп ителгән. Татарстан авторлары арасында – Искәндәр Измайлов, Айдар Ногманов, Айдар Хәбетдинов, Радик Салихов, Илдус Заһидуллин, Илшат Зарипов, Сәид Шәһабиев, Резеда Сафиуллина-Ибраһимова һәм башкалар бар.

Рәфикъ әфәнде рус телендә басманың якын арада 1000 данә тираж белән дөнья күрәчәген, китапханәләрдә, мәдрәсәләрдә һәм ислам югары уку йортларына таратылачагын хәбәр итте. Китап февраль-март айларында ук «Фән» нәшриятында өстәмә тираж белән чыгачак. Монографиянең инглиз һәм гарәп теле версияләре быел җәй һәм көз айларында көтелә.

Эльмира СИРАҖИ.

Дирижерга истәлек тактасы

Казанның Карл Маркс урамында, ТАССРның халык артисты Фуат Мансуров яшәгән йортта мемориаль такта ачылды.

Тантанада Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова Ф.Мансуровның йөз еллыгын билгеләп үтүгә әзерлек эшләре башлануы турында хәбәр итте. «Аның традицияләрен дәвам итүчеләр өчен Фуат Мансуров исемендәге яңа премия, конкурс, стипендияләр булыр дип өметләнәм», – диде ул.

Чарада дирижерның кызы – Марина Мансурова да катнашты. «Әтинең эшкә тугры булуына, чыдамлыгына сокланып яшәдем. Ул бик шаян, шул ук вакытта җитди кеше иде. Юморны ярата иде. Әтине искә алып яшәрбез дип ышанам», – диде ул.

Татарстанның атказанган артисты, Казан дәүләт консерваториясе профессоры Илсур Айнатуллов Фуат Мансуров белән бергә эшләгән елларын искә алды: «Фуат ага Татарстанны, татарларны бөтен дөньяга танытты. Гастрольләр белән кая гына барсак та, Фуат Шакировичның укучылары аны рәхмәт әйтеп каршы ала иде. Ул полиглот та булды. Французча барсак – французча, Германиядә – немецча, инглизчә сөйләшә иде», – диде Илсур Айнатуллов.

Истәлек тактасының авторы – скульптор Фәнил Вәлиуллин. Фуат Мансурова Мәскәүнең Троекуров зиратында куелган кабер ташын да ул ясаган.

Җәлилчене мәңгеләштерделәр

Казахстанның Кызылорда шәһәрендә нибары мең ярым тирәсе татар исәпләнә. Әмма алар, сан ягыннан күп булмаса да, иҗтимагый актив тормыш алып бара. Шәһәрдәге 112 нче мәктәп исә милләттәшебез, уку йортының беренче директоры Нәгыймә Әхмәдиева исемен йөртә. Гомер буе укытучы булып эшләгән ханым 1952 елда Кызылордада үзе карап төзеткән мәктәптә директор була һәм уку йортын 26 ел дәвамында җитәкли. Аны үз эшенә ихластан бирелгән җитәкче буларак хәтерлиләр. Нәгыймә Әхмәдиева, 1991 елда татар үзәген ачу тәкъдиме белән чыга. Аның тырышлыгы белән бар ителгән үзәк бүген дә актив эшчәнлек алып бара.

Бөтендөнья татар конгрессының Төбәк тарихын өйрәнүчеләр белән эшләү комитеты җитәкчесе, тарихчы галим Альберт Борһанов хәбәр иткәнчә, былтыр мәктәпкә 70 ел тулуны зурлап тантаналы рәвештә билгеләп үткәннәр. Нәгыймә апа турында истәлекләр дә барланган, хәтирәләр яңартылган.

Тарихчы галим шушы көннәрдә Кызылорда өлкәсендәге Казалы (Казалинск) шәһәренең 16 нчы мәктәбендә тагын бер милләттәшебезне хөрмәтләү тантанасында катнашты. Уку йорты бинасында патриот шагыйрь, Советлар Берлеге каһарманы Муса Җәлилнең көрәштәше, Беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры Фоат Хаҗиәхмәт улы Сәйфелмөлековка тантаналы рәвештә мемориаль такта куелган. Аның нәкъ шул лицейга урнаштырылуы очраклы түгел. Милләттәшебезнең язмышы Казалы мәктәбе белән турыдан-туры бәйле. Ул анда 1925 елдан 1933 елга кадәр укыган. «Укучылар һәм педагоглар бу чорның күренекле каһарманы турындагы истәлекләрне барлап, 11 җәлилче белән бергә палач балтасыннан гомере өзелгән милләттәшебезнең исемен мәңгеләштерделәр», – диде А.Борһанов.

Мемориаль такта кую турындагы тәкъдим белән җирле халык мөрәҗәгать иткән. Бу эшне башкарып чыгу өчен ике ел вакыт кирәк булган. Фоат Сәйфелмөлеков турындагы материаллар җыюда Кызылорда өлкәсенең татар иҗтимагый-мәдәни үзәге ярдәм күрсәткән.

Ф.Сәйфелмөлеков 1941 елда 25 яшендә фронтка китә. 1944 елның 25 августында Берлинның Плетцензее төрмәсендә башлары киселгән 11 татар арасында Фоат Хаҗиәхмәт улы да була. Кызылорда өлкәсенең татар иҗтимагый-мәдәни үзәге шәһәр хакимияте җәлилче каһарманның исемен киләчәктә Казалының берәр урамына да бирер, дип тә ышана.

Сөембикә КАШАПОВА.

Мөселманнарны спорт берләштерде

Казанда ислам илләре арасында халыкара хоккей турниры үтте. Ярышлар ир-ат һәм хатын-кыз командалары арасында оештырылды. Татарстан башкаласына барлыгы 13 илнең җыелма командалары килде. Алар арасында Бәхрәйн, Согуд Гарәбстаны, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Марокко, Төркия һ.б. дәүләтләрнең командалары булды. Турнир кысаларында «Ислам илләрендә хоккейны үстерү берләшмәсе»н төзү турында килешүгә кул куелды. **1 нче биттә** – хоккей ярышының ачылыш тантанасы күренеше (Владимир Васильев фотосы, «Татар-информ»).

Татарлар кимемәгән

Мәгълүм булганча, 2022 елның 31 декабрендә Росстат 2021 елда Россиядә узган халык санын алу мәгълүматлары нәтиҗәсен игълан итте. 2010 елгы җанисәптә 5310649 кеше үзен «татар» дип күрсәткән булса, 2021 елгы җанисәптә – 4713669 милләттәшебез теркәлгән. Рәсми саннар ике җанисәп арасында татарларның 600 мең кешегә кимегәнен күрсәтә. Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат очрашуында Россиядә татарларның саны чынлыкта 5,5 миллионнан да ким булмавын, халкыбызның сан буенча Россиядә икенче урынны саклап калуын әйтте. «Мин моны Бөтендөнья татар конгрессының экспертлары бәяләмәсе нигезендә 10 ел эчендә алып барылган эшчәнлеккә дә таянып әйтәм. Татарстанның да, татар халкының да абруе Россиядә һәм дөньякүләм дәрәҗәдә артты һәм милли үзаң да түбән түгел», – диде ул.

Комитет җитәкчесе бу уңайдан 2013 елда уздырылган Универсиаданы, 2015, 2018, 2019 елларда Татарстанда үткән Дөнья чемпионатларын, 2020 елда югары дәрәҗәдә билгеләп үтелгән ТАССР-ның 100 еллыгы һәм Болгарда Ислам динен рәсми кабул итүгә 1100 ел тулуы да республикабызны һәм татар халкын тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрүен әйтте. Шунысын да искә алырга кирәктер: Бөтендөнья татар конгрессы үз составында дөнья күләмендә сибелеп яшәүче татарларның биш йөзгә якын оешмасын берләштерә. Аларга таянып үзенең устав эшчәнлеге кысаларында конгресс халык санын алу кампаниясенә даими рәвештә әзерлек эшләрен алып барды. «Шуңа да без, Россиядә татарлар саны 5,5 миллионнан да ким түгел дип әйтә алабыз. Татарларның бер өлеше төрле сәбәпләр аркасында үз милләтен күрсәтмәүче 16,6 миллион кеше арасына кергән», – диде Данис Шакиров. Ул моны халык санын алу вакыты ковид зәхмәте котырган чорда булуы һәм милләттәшләребезнең бер өлеше җанисәптә катнаша алмавы, сан алучыларның да һәр кешегә дә барып җитү мөмкинлеге булмавы белән аңлатты. Аннары 2010 елда үткән җанисәп нәтиҗәләр буенча Россиядә 5 миллион 600 мең кеше үзенең милләтен күрсәтмәгән булса, 2021 елгы халык санын алуда 16 миллион 600 мең кешенең милләте тәгаенләнмәгән. «Татарларыбызның югалган санын шулар арасыннан эзләргә кирәк», – диде башкарма комитет җитәкчесе.

Матбугат очрашуында катнашкан тарих фәннәре докторы, этнолог Дамир Исхаков үз милләтен күрсәтмәүчеләрнең күп булуы бу кешеләр турында мәгълүматның дәүләт органнарыннан алынган булуын әйтте. «Мин озак еллар дәвамында халык санын алу кампанияләрендә катнашам. Камил узган җанисәпләрне гомумән хәтерләмим. Россиянең иң күренекле демографлары тануынча, 2021 елгы халык санын алуда җитешсезлекләр гадәттәгедән дә артыграк булды. Милләтен күрсәтмәгәннәр бик күп. Димәк, бу кешеләргә җанисәп алучылар килеп җитмәгән һәм алар турында мәгълүмат полиция чыганакларыннан алынган, ә ул чыганакларда милләт күрсәтелми», – диде Дамир Исхаков.

Сөембикә КАШАПОВА.

Кодрак ханга һәйкәл

Самара өлкәсенең Ширяево авылы янындагы тауда Кодрак ханга һәйкәл куелган. Тарихи мәйданчыкка таш сынны «Болгар мирасы» мәдәни-тарихи фонды урнаштырган.

Биш тонналы һәйкәлне Болгариядән алып кайтканнар. Аны танылган Болгар скульпторы Дишко Дишков ясаган.

«Кодрак сынын урнаштыру – ул истәлек генә түгел, ә тарихи вакыйга да. Кодрак хан җитәкчелегендәге кабиләнең бер өлеше, VII гасырда Бөек Болгариядән Урта Идел буена күченеп, борынгы Болгар дәүләтен төзегән һәм Урта Иделгә һәм Көнчыгыш Европага зур үзгәрешләр кертүгән. Болгар кабиләләре шәһәрләр, университетлар, алга киткән сәүдә, һөнәрчелек белән прогрессив дәүләт төзегән, – ди «Болгар мирасы» фонды рәисе Гомәр Батыршин. – Соңрак һәйкәлгә гранит такта урнаштырачакбыз, гомуми юлдан тарихи мәйданчыкка кадәр 250 метр озынлыктагы тротуарны төзекләндерәбез һәм сукмак буенда өстәмә яшелләндерү эшләре башкарылачак. Яз көне һәйкәлне рәсми рәвештә ачу планлаштырыла».

ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ МУЗЕЕ

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Диварларда Равил аганың якташларына, аның каләмдәшләренә дә урын мул бирелгән. Кадыйр Сибгатуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Мансур Шиһапов, Хәлим Җәләй – һәммәсе әле бүген дә сагындырып, күңелләрне сызландырып тора. Барчасы да исән чакта бер-берсенә терәк һәм илһамдаш булып яшәргә тырышты, барчасы да шигърият мәйданында үз учагын яндырып өлгерде, алар бүген дә безнең янәшәдә...

Кунакларның иң зурлары да килә башлагач, мирасханә барча кешене дә сыйдыра алмас булды. Ниһаять, музей ачу тантанасын башлап җибәрделәр. Музей Татарстан Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды булышлыгында ачылган икән, шул хөрмәттән тәүге сүзне әлеге фондның башкарма директоры Нурия Һашимова алды. Аннан соң чыгыш ясаучы Балык Бистәсе район башлыгы Радик Ислямов, Татарстан Дәүләт Советы рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, республика мөфтиятенең баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, «Татмедиа» республика агентлыгының генераль директоры Айдар Сәлимгәрәев, «Татмедиа» акционерлар җәмгыятенең генераль директоры Шамил Садыйков, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, Башкортстан Язучылар берлегенең әле бер ай элек кенә сайланган яңа рәисе, дустыбыз Айгиз Баймөхәммәтов h.б. – һәммәсе дә халык шагыйре Равил Фәйзуллинны алда көткән юбилей елында шушы мирасханә ачылу белән тәбрикләде. Хезмәттәшебез Равил ага да, җавап сүзендә, музей ачу өчен хезмәт куйган һәркемгә рәхмәт сүзләре ирештерде.

Равил ага, һичшиксез, бәхетле. Менә аның үз мәктәбе һәм музее да бар. Ә күңелне әрнетеп, хәтер аша туган җирендә һичнинди ядкәре калмаган Әмирхан Еники кебек олуг шәхес йөгереп уза. Ул үзенең туган җире – Башкортстандагы Благовар районының Каргалы авылында түгел, ә Казанга китеп яшәде һәм андагы татар милләтенә хезмәт итте бит, дигән сылтау белән, күрше республика башлыкларының бер генә мәктәп яки тыкрыкка да аның исемен кушканы юк, музей булдыру турында сүз кузгату да артык. Ә Фадеев, Шолохов, Островскийлар, хәтта һәммәбез өчен уртак булган Чыңгыз Айтматов – Уфа каласына килеп, башкорт милләтенә хезмәт иткәнмени?.. Тагын дәвам итсәк, Башкортстанның Яңавыл районында туып-үскән Нурихан Фәттах, Әдип Маликов, Сәҗидә Сөләймановалар башкорт милләтенә хезмәт итмәгәнме? Үз милләтебез акыннарының үз җирендә шушы тикле типкәләнеп йөрүе бик кызганыч...

Быел август аенда Равил агабызга 80 яшь тулачак. Кунакларны иҗаты белән таныштыру, туган җиренең һавасын сулату өчен тагын бер мирасханә – изге урын артты. Котлы булсын, эшчәнлеге дәвамлы барсын! Тик менә мәктәбендә 25 укучы гына торып калган икән. Бусы бик кызганыч...



Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН һәм Салават КАМАЛЕТДИНОВ фотолары.

● Илкүләм рейтинглар агентлыгы МДУ белән бергә үткәргән тикшеренү нәтиҗәләре буенча, Татарстан Россиянең туристлык тотрыклы үскән төбәкләренең беренче бишлегенә кертелгән. Краснодар крае - беренче, Санкт-Петербург – икенче, Мәскәү – өченче, Казан – дүртенче урында.

● Казанның Ямашев проспекты 2022 елда Россиядә иң кыйбатлы сәүдә урамы дип табылган. Анда аренда бәясе елына бер квадрат метрга 35 мең сумга кадәр тәшкил иткән. Беренче өчлеккә тагын Иркутск һәм Воронеждагы урамнар кертелгән.

● Россиядә бер миллиардер, санкцияләрдән куркып, берьюлы ике Maybach автомобилен сатып алган – берсе ватылса, икенчесен запчастька тотарга ниятләгән. Mercedes Россиядән китүе турында октябрь аенда белдерде. Германия автоконцерны Россиядә машиналар җыюны инде мартта ук туктаткан иде. Моннан тыш, илгә Европа Берлегеннән бәясе 50 мең евродан арткан, АКШтан исә теләсә нинди автомобильләрне кертү туктатылды.

ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬКӘ ГРАНТ ЯРДӘМЕ

Татар халкының мәдәниятына багышланган әдәбият һәм сәнгать әсәрләренә Мәдәният министрлыгы гранты ияләре билгеле.

Грантның төп юнәлешләре – әдәбият, музыка, театр, рәсем сәнгате, халык сәнгать һөнәрләре, мәдәни тикшеренүләр, сынлы сәнгать, кино. Грантның гомуми суммасы 9,8 млн сум тәшкил итә.

Иң зур грант – 500 мең сум – проза яки поэзия жанрында зур әдәби әсәр өчен биреләчәк. Шундый өч грант каралган.

«Татар телендә кече формадагы әдәби әсәрләр (проза, поэзия)» номинациясе –100 мең сум:
1. Айзирәк Гәрәева – «Бирүзә йорт» повесте.
2. Амур Фәләхов – «Җан авазы» хикәясе.
3. Рифат Корбанов (Рифат Җамал) – «Яшим әле» поэтик циклы.
4. Фирүзә Фәтхетдинова – «Карга боткасы» шигырьләр циклы.
5. Фәнил Гыйләҗев – «Әдипләр йөзе» шигырьләр циклы.
6. Нәбирә Бикчурова (Гыйматдинова) – «Ике рәссам» («Карт һәм яшь)» повесте.
7. Лемон Леронов (Ләбиб Лерон) – «Мин дөньяны күрәм» повесте.

«Татар телендә эре формадагы әдәби әсәрләр (проза, поэзия)» номинациясе –500 мең сум:
1. Зиннур Хөснетдинов (Зиннур Хөснияр) – «Әллүки» романы.
2. Рәдиф Сәгъди – «Гасырга сузылган бер мизгел» романы.
3. Рөстәм Галиуллин – «Галимҗанов эше» повесте.

«Балалар өчен әсәрләр (проза, поэзия, комиксы)» номинациясе – 100 мең сум:
1. Айсылу Шәехова (Айсылу Имамиева) «Путешествие на высоте» повесте.
2. Илсөяр Гарипова (Иксанова) – «Туган тел» шигырьләр циклы.
3. Алмаз Гыймадиев – «Сәер хат» повесте.
4. Лилия Тимербаева –Казанның кызыклы язмышлы матур йортлары турында комикслар.
5. Сәлимә Аскарова – «Гөлчәчәк. Кайту» комиксы.
6. Рифат Сәлахов – «Кошлар әлифбасы» шигырьләр җыентыгы.

«Татар телендә драма әсәрләре (драма театрлары өчен, курчак театрлары өчен пьесалар, тәрҗемәләр)» номинациясе – 200 мең сум:
1. Гөлназ Нуретдинова – «Илдус белән Котдус маҗаралары» пьесасы.
2. Луиза Шарова (Луиза Янсуар) – «Кайту» циклы: «Гөрләгән сулар башында...», «Бүзләрем маналмадым…», «Видагъ» (драма театрлары өчен пьеса-эзләнү).
3. Айдар Әхмәдиев – «Кави-Сәрвәр» либреттосы.
4. Ркаил Зәйдуллин – «Картларга орден кирәк» пьесасы.

«Татар телендә тулы метражлы нәфис фильм өчен киносценарийлар» номинациясе – 175 мең сум:
1. Азат Зарипов, «Балакаем».
2. Мансур Гыйләҗев, «Тугызынчы дулкын».

«Татар телендә кыска метражлы нәфис фильм өчен киносценарийлар» номинациясе – 75 мең сум:
1. Салават Юзеев – «Абага чәчәге» (Ркаил Зәйдулланың повесте мотивлары нигезендә).
2. Ренат Хәбибуллин – «Түбәтәй» фильмы.

«Сәнгати эзләнүләр» номинациясе – 200 мең сум:
1. Риф Гатауллин – «1940-2010 елларда татар композиторлары» антологиясе.
2. Рөстәм Шәмсутов – «Урта Идел һәм Урал буе татарларының заманча гарәп графикасы сәнгате: традицияләр һәм новацияләр».
3. Елена Шевченко – «Татар балалар театры яңа формалар эзләүдә».

«Скульптура» номинациясе – 200 мең сум:
1. Александр Дресвянников –А.Х.Халиковка һәйкәл эскизы.
2. Динә Сергухина – «Әкият» курчак театры актерларына багышланган композиция.

«Сынлы сәнгать» номинациясе – 200 мең сум:
1. Хәмит Латыйпов – «Кич» картинасы.
2. Равил Заһидуллин – «Ау станы» тематик картинасы.
3. Васил Заһретдинов – «Изге Дога» картинасы.

«Декоратив-гамәли сәнгать» номинациясе – 300 мең сум:
1. Наилә Кумысникова – «Болгар хәзинәсе» панносы.
2. Әлфия Ильясова (Саргин) – «Татар әкияте келәме» декоратив-гамәли сәнгать әсәре.
3. Ринат Әхмәтов – «Минем гаилә» декоратив-гамәли сәнгать әсәре.

«Татар телендә музыкаль-театр жанры (опера, балет, музыкаль комедия, мюзикл)» номинациясе – 500 мең сум:
1. Рәшит Кәлимуллин – «Ак аккош» балеты.
2. Луиза Батыр-Болгари – «И, Сабан туй – тамаша!» опереттасы.

«Хореография» номинациясе – 200 мең сум:
1. Энҗе Дусаева – «Ха-Тын» пластик спектакле.
2. Алена Харисова – «Карга боткасы» хореографик куелыш.
3. Венера Галимова – «Кыз» пластик спектакле.

«Музыкаль әсәрләр (симфония, хор әсәре, камера-инструменталь әсәрләр, камера-вокаль әсәрләр)» – 200 мең сум:
1. Миләүшә Хәйруллина – «Шагыйрь» симфоник хор поэмасы.
2. Зөлфия Кудоярова (Рәупова)– «Алтын кәләш» симфоник әкияте.
3. Илфат Дәүләтшин – «Мыраужан хәйләсе» балалар өчен хор циклы.
4. Елена Анисимова – «Идел буе әкиятләре» оркестр сюитасы.
5. Илһам Байтирәк – «Идел офыклары» симфониясе.
6. Эльмир Низамов – хор өчен «Бакый Урманче» кантатасы.
7. Лилия Таһирова – камера оркестры һәм хор өчен «Сабан туй сөлгесе» поэмасы.
8. Рөстәм Зарипов – татар шагыйрьләре шигырьләренә «Кышкы маҗаралар» кантатасы.

Министрлык сәнгать әсәрләре иҗат итү нәтиҗәләренә ирешү өчен грант бәйгесе җиңүчеләре белән конференция үткәрергә планлаштыра.

Грант алучы әсәрен 2023 елның 10 декабреннән дә соңга калмыйча иҗат итеп бетерергә тиеш.

Конкурска барлыгы 120 гариза кабул ителгән.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

Җанисәп чын вәзгыятьне күрсәтми



Дамир ИСХАКОВ, тарих фәннәре докторы, этнограф:

– Безгә күрсәтелгән саннар чын вәзгыятьне күрсәтми. Татарларның күпчелеге эре шәһәрләрдә яши. Ә фатирларның өчтән беренә халык санын теркәүчеләр керми. Алар полиция чыганаклары аша исәпкә алына. Полиция чыганакларында ике әйбер телгә алынмый – туган тел һәм милләт. Димәк, халкыбызның бер өлеше югалуы шушы сәбәп белән бәйле.

Халыкны исәпкә алу нәтиҗәләрендә туган тел мәсьәләсе буенча да мәгълүматлар чыкты. Шуннан татарлар арасында туган телен белүчеләр кискен кимегән икәне дә аңлашыла. Ул 2010 елдан бирле, ягъни шундый кыска вакыт аралыгында болай нык кими алмый. Мәгълүмат кешеләрнең үзаңыннан түгел, полиция чыганакларыннан алынган вакытта гына шундый саннар килеп чыгарга мөмкин.

Узган җанисәпләр вакытында башкортлар арасында безнең 200 мең кеше калган иде. Хәзер дә алар бер өлешне «чукып» алгандыр дип уйлыйм. Бөтен халыкларның саны кимегән вакытта башкортларның 100 меңгә артуы шуны күрсәтә. Безнең хисапка күпмегә арткannарын төгәл белемни, әмма районнар буенча материаллар чыккач, моны санап булачак.

Ассимиляция хисабына да татарның бер өлеше үзен башка милләт дип танырга мөмкин. Әмма 10 ел эчендә шундый күп халыкның милләтә үзгәрми.

Татарстан җитәкчелегенә, сәясәтчеләргә җанисәпнең әчтәлеге, сыйфаты буенча бәя бирергә туры киләчәк. Алар Мәскәүгә, федераль органнарга: «Ни өчен шулай килеп чыкты?» – дип мөрәҗәгать итәргә, үзләренең фикерләрен, мондый нәтиҗәне танып булмавын ачык итеп әйтергә тиеш.

Үзем бу җанисәптә татарларның 500 меңгә кимүен фаразлаган идем. Мин уйлаганнан да күбрәк килеп чыккан. Ләкин безгә пессимизмга бирелергә ярамый. Физик яктан татарлар бар, аларны дөрес итеп санарга гына кирәк.

Санауны ничек итеп оештырырга – анысы башка сорау. Конгресс тарафыннан оештырырга, дигән фикерләр дә чыкты, тик минемчә, бу мөмкин түгел. Әгәр Татар конгрессының барлык филиаллары бик яхшы эшләсә, халыкара мөнәсәбәтләре тыгыз булса, ул вакытта аңа ышанып булыр иде әле. Әмма хәзерге вакытта андый мөмкинлекләр юк дип уйлыйм.

Тагын 10 елдан соң үткәреләчәк җанисәптә, илдәге сәяси вәзгыять башка төрле булса, икенче төрле нәтиҗәләр дә килеп чыгарга мөмкин.

Илдар ГАБДРАФИКОВ, тарих фәннәре кандидаты, сәясәт белгече:

– Нәтиҗәләрне алдан чамаладым, әмма татарлар саны бу кадәр үк кимер дип көтмәгән идем. Россия буенча 600 мең кеше кимү – бу нык күп! Әлеге сан безне сагайтырга тиеш. Бу саннар җанисәпнең сыйфатсыз үтүен күрсәтә.

Идел буендагы халыкларда балалар саны бер чама. Мордва, мари һәм чуашлар белән чагыштырганда, ассимиляция дә татарда кимрәк. Миграция дә бездә көчле дип әйтеп булмый. Димәк, җанисәптә татарның шулай нык кимүен демография һәм ассимиляция белән генә аңлата торган түгел.

Монда бүтән йогынты да булгандыр. Фальсификацияме, махсус киметүме – анысын әлегә әйтә алмыйм. Һәрхәлдә, биредә галимнәргә генә түгел, Татарстан җитәкчелегенә дә өйрәнергә, уйланырга җирлек бар. 10 ел эчендә шулай кимү – башка сыймый торган хәл. Татар иҗтимагый оешмалары берни эшләмәгән очракта да без болай ук кимергә тиеш түгел идек. Татарларның гомуми санының 10 %ы дигән сүз бит бу!

Башкортстанда татарларның ничек кимүләре аңлашыла – башкортлар арткан, татарлар кимегән. Димәк, башкортлар безнең исәпкә артканнар. Чынлыкта барыбер татар – татар, башкорт – башкорт булып кала. Ә кәгазьгә теләсә нинди сан язарга мөмкин. Ләкин Россия буенча башкортлар саны да кимегән бит.

Татар зыялыларының җанисәп алдыннан Башкортстанга йөрүенә килгәндә, аның зыяны булмагандыр. Тик ул диңгездәге тамчы кебек кенә.

intertat.tatar

ДАСТАННАРДА – милли тарихыбыз

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов узган елның октябрь аенда Дәүләт Советына еллык Юлламасында республикабызда 2023 нче елны Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы дип игълан иткән иде. Аның кысаларында Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы утырышында агымдагы ел «Дастаннар елы» дип билгеләнде. Күптән түгел «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында Дастаннар елына багышланган матбугат очрашуы да узды.

● «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында матбугат очрашуы.



● 2006 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Идегәй» дастаны.

● Рәссам Байназар Әлменовның «Идегәй» дастанына ясаган рәсеме.

1917 елгы революциягә кадәр әби-бабаларыбыз дастаннарны кулдан-кулга күчереп язып үзләрендә саклассалар да, аларны озын кышкы кичләрдә укып юансалар да, хәзерге вакытта халкыбыз арасында дастаннар турында белүчеләрне бармак белән генә санарлык. Галимнәребез теркәгән 100 дән артык дастан арасында «Түләк белән Сусылу», «Ак күбек», «Кисекбаш», «Алпамыш», «Кыйссаи Йосыф», «Сәйфелмөлек кыйссасы», «Таһир һәм Зөһрә», «Ләйлә белән Мәҗнүн» һәм «Идегәй» милләттәшләребез арасында аеруча киң таралган. Әмма галимнәребез искәрткәнчә, бүген милли тарихыбыз мәктәпләрдә бик аз укытыла, аеруча дастаннарыбыз турында саран мәгълүмат бирелә. Сигезенче сыйныфта гына «Идегәй» турында кыска мәгълүмат булып ала. Башка дастаннарны балалар белми. «Балаларыбызның милли аңын үстерү ысулларын булдырырга кирәк. Моңа дастаннар аркылы ирешеп була. Шул ук вакытта кыргызлар, казахлар, азәрбайҗаннар, башкортлар үз дастаннарын мәктәпләрдә укыталар. Аларда балалар дастаннарны хәтта яттан сөйли. Без ул яктан артта калабыз», – ди тарих фәннәре докторы, этнограф Дамир Исхаков. Галим дастаннар буенча аерым хрестоматия чыгарырга кирәклеген дә искәртә. Әлбәттә, әсәрләр катлаулы, аларны эшкәртмичә биреп булмаячак. Дастаннарны өйрәнү балаларда гомумән, киң җәмәгатьчелектә милли үзаң тәрбияли торган бер ысул булып торуын да әйтергә кирәктер. Галим, китаплар белән генә чикләнмичә, дастаннарга нигезләнгән спектакльләр, мультфильмнар, кинолар эшләргә кирәклеген ассызыклый. «Күптән түгел «Шаян ТВ»ны караганда, Америка мультфильмнарының күрсәтелми башлаганын күрдем. Татарчага тәрҗемә ителгән рус мультфильмнары да аз. Дастаннарга нигезләнеп, үзебезнекен эшләргә мөмкин ләбаса. Алар «Гарри Поттер»дан ким булмас иде», – ди ул.

«Дастаннарны эпик әсәр төре буларак кына түгел, ә бәлки тарихны чагылдырган милли аң һәм милли рух чыганагы буларак кабул итәргә кирәк», – ди Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров.

Филология фәннәре кандидаты Фәнзилә Җәүһәрова булганы белән канәгатьләнеп килүебез нәтиҗәсендә искиткеч зур байлыгыбызга игътибар кимүен искәртте. «Акбүз ат»ны башкортлар үзләренеке генә итеп сөрән салды. Күренекле галимебез Фатих Урманчеев та «Татар мифологиясе» өч томлыгында Акбүз атны күбрәк башкортларда очрый дип бирә. Акбүз ат (канатлы ат) образы татар әсәрләрендә дә бар. «Йөртешлек», «Түләк белән Сусылу» кебек татар дастаннарында да Акбүз атлар бар. Ул аларда да мифик көчкә ия. Акбүз ат образын Себер ягында яшәүче татарларның «Канатлы ат» әкиятендә дә күрергә мөмкин. Соңрак бу әкиятнең төп вакыйгаларын Петр Ершов үзенең «Конек-Горбунок» әсәренә керткән. Ул үзе үк поэманың сюжетын Себер татарлары әкиятеннән алуы турында яза. Без аны бала чакта яратып укыдык. Аның башлангычы безнең дастаннарда ята», – диде Ф.Җәүһәрова. Күренекле галимебез Нәкый ага Исәнбәт Бөек Ватан сугышына кадәр үк, 28 чыганакны туплап, «Идегәй» дастанын төзи. Нәкый ага, башкалардан аермалы буларак, чәчмә дастанны тулысынча тезмә итеп үзгәртә. Шигырь юлларын күп кенә мәкаль-әйтемнәр белән бизи. «Идегәй» дастаны Н.Исәнбәт эшкәртүендә 1940 елда «Совет әдәбияты» журналының 11-12 нче саннарында басылып чыга. Нәкый Исәнбәт «сәнгать реставраторлыгы» юлы белән дастанны иҗади торгызып, аны татарның борынгы гореф-гадәтләре, казанышлары, дәүләт тоту тәртибен, идеалын, омтылышын, холык-фигылен сурәтләнгән тарихи-фәлсәфи роман дәрәҗәсенә җиткерә. «Әсәрдә татар милли галәме бөтен тирәнлеге, бизәкләре белән бирелгән» – ди Ф.Җәүһәрова. Галимә шул ук вакытта татар мәктәбен тәмамлаган яшьләрнең «Идегәй»дән аз хәбәрдар булуын, аны шартлы рәвештә генә белүен дә әйтте. Чөнки ул – шактый катлаулы әсәр.

Дастаннарыбыз галимнәребез тарафыннан өйрәнелә. Бу уңайдан Ф.Җәүһәрова Вилгельм Радловның беренче тапкыр татар дастаннарына игътибар итүен искә төшерде. Галим бигрәк тә Себер җирлегендә яшәп килгән дастаннарны туплый һәм 1866 елда Петербургта «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи» дигән хезмәтен бастырып чыгара.

Дастаннар елы игълан ителүне галимнәребез дә шатланып кабул иткән. Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары, филология фәннәре кандидаты Олег Хисамов институт галимнәре арасында фольклорчы галим, филология фәннәре докторы Фатих Урманчеевның дастаннарны беренчеләрдән булып күтәреп чыгуын әйтте. Ул бигрәк тә бәет, дастан, риваять, йола җырлары, уеннары кебек борынгы төрләрнең туу һәм формалашу тарихын өйрәнүгә зур игътибар биргән. Фатих аганың «Дастаннарга лаек замана: борынгы фольклор, хәзерге поэзия» дигән хезмәте соңрак башка төрки халыкларның да өстәл китабына әверелә. Галимнең шулай ук «Героический эпос татарского народа» дигән хезмәте әһәмияткә ия. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты 1994 елда Ф.Урманчеевның «По следам Белого волка: ранние этнокультурные связи тюрко-татарских племен» дигән хезмәтен бастырып чыгара. Галимнең «Народный эпос «Идегей», «Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә» кебек хезмәтләре дә – күп кенә яшь галимнәребез өчен дәреслек. Соңрак институтта Фатих аганың эшчәнлеген аның укучылары дәвам итә. 2000 елда филолог, публицист, фольклорчы, филология фәннәре докторы Лилия Мөхәммәтҗанова «Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны» дигән темага кандидатлык, «Татарский эпос: книжные дастаны» дигән темага докторлык диссертацияләре яклый. Филология фәннәре докторы Илсөяр Закирова да докторлык дисертациясе өчен «Эпический фольклор периода Золотой Орды: мифологические и исторические основы» дигән теманы сайлаган. Бүгенге көндә институтта дастаннарны өйрәнү эше дәвам итә. Филология фәннәре кандидаты Гөлнира Хөсәенованың «Таһир белән Зөһрә» сюжетлы дастаннар: өйрәнелү дәрәҗәсе, кулъязмалары һәм сөйләмә вариантлары» дигән саллы мәкаләсе күпләрнең игътибарын җәлеп иткән. Дастаннарыбыз темасы буенча фәнни эшчәнлек алып баручы галимнәребезнең дистәдән артык хезмәте һәм монографияләре басылып чыккан.

Институт хәзерге көндә рус телендә 15 томлык «Татар халык иҗаты» дигән хезмәтне әзерли. Бер үк вакытта аның 25 томлык татар телендәге варианты да эшләнә. Томлыкның «Дастаны» дигән өлеше басылып чыккан инде. Татар телендәге вариантында дастаннарга ике том бирелгән. Алар инде эшләнеп беткән. Әкиятләр буенча җиде томлык нәшер ителү алдында. Сентябрь аенда институт галимнәре семинар-конференция форматында дастаннар турында сөйләшү уздырырга ниятли. Алар шулай ук дастаннарның фәнни нигезенә багышланган берничә җыентык чыгарылачагына да ышандыра.

Данис Шакиров Татарстанда һәм Россия төбәкләрендә Бөтендөнья татар конгрессы канаты астында эшчәнлек алып барган татар оешмалары тарафыннан да ел дәвамында уздырыла торган чараларны шушы милли дастаннарыбызга бәйләп оештырылачагын ассызыклап үтте. Дастаннарны балаларга һәм киң катлам җәмәгатьчелеккә җиткерү юлларын һәм ысулларын булдырачаклар, мульфильмнар эшләү, Татарстан Язучылар берлеге белән бергә дастаннар сюжетына нигезләнгән драма әсәрләрен сәхнәләштерү мәсьәләсе дә алга куела. Шушы көннәрдә К.Тинчурин театрында «Идегәй» дастаны буенча әзерләнгән спектакльнең премьерасы көтелә. Шул ук вакытта социаль челтәрләрдә дастаннардагы вакыйгаларга нигезләнгән каһарманнарны күрсәтә белүгә һәм аларның татар халкыныкы икәнлекләрен исбатлауга да игътибар биреләчәк. Безнең төрки халыклар белән уртак шактый каһарманнарыбыз бар. Алар чынлыкта татарныкы. Трагик сюжетка корылган аерым бер дастаннарыбыз бар. Әгәр бүген без бу эшне башлап җибәрмибез икән, алар югалачак, башка халыкларныкы булып калачак. Дастаннарга багышланган әсбапларны аерым кулланма буларак чыгару мәсьәләсе дә игътибар үзәгенә куелырга тиеш. «Идегәй», «Түләк һәм Сусылу» кебек катлаулы дастаннарыбызны барлык катламнар да аңлый алырдай дәрәҗәгә җиткерү сорала. Төп бурычыбыз исә – дастаннар аша милли аңны үстерү. Шушы нияттән фәнни-гамәли конференцияләрдә, «түгәрәк өстәл» утырышлары да, җыеннар да, социаль челтәрләрдә эшчәнлек тә милли дастаннарыбыз темасын уртага алып үткәрелер, дип уйланыла.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Шамил МАННАПОВ

Ботакларым ботарласалар да, Тамырларым, шөкер, сау әле...

(Танылган шагыйрь һәм прозаик, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Һ.Такташ исемендәге әдәби бүләк иясе Шамил Маннаповның тууына 85 ел)

КАБАТЛАНА КАЛСА...

Ай-һай, дөнья, туйдым синнән,
Син дә туйгансың миннән.
Шушы яшьләремә җитеп,
Ни рәхәт күрдем синнән...
Эти җыры

«Нигә икән һәр җан иясенә
Тик бер генә гомер бирелгән?
Кышлардан соң язлар килгән кебек,
Кабатланса иде гомерләр...» –

Әй кордашым, шулай дисең дә бит,
Бармы икән моның кирәге?
Үз гомерендә узган сиратларны
Икенче кат узар өчен тагы
Түзәр микән адәм йөрәге?
Ничек булыр алдан күреп тору
Кабатланып узар юлыңны?
Хәтта кайчан Әҗәл килачәген
Шәпме булыр белеп торуы?

Юк!
Күрәчәгең алдан белеп торсаң,
Башың чыкмас кайгы-газаптан.
Ни дисәң дә, Ходай бу дөньяны
Бик тә камил-серле яраткан.
Шөкер итеп кенә яшисе дә
Якты бу дөньяга килгәнгә,
Юк шул,
Дөнья камил булганда да,
Камиллектән ерак бу бәндә.

Җирдә яшәү тик бер бирелгәнен
Белгән хәлдә,
Никтер каныгып,
Кеше җанын йә үзенең җанын
Кыючылар тора табылып...

Кышлардан соң язлар килгән кебек,
Кабатлана калса гомерләр,
Нишләмәс бу бәндә?! –
Шуңа бугай
Тик бер гомер аңа бирелгән...

ВАСЫЯТЬНАМӘ ЯЗА КЕМНӘРДЕР...

Бу дөньядан киткән чакта шунысы
Үкенечле булыр барсыннан:
Яңа гына туган соңгы җырым
Елап калыр сыман артымнан...

Васыятьнамә яза кемнәрдер,
Малы бардыр, ахры, җитәрлек.
Ә мин андый мәшәкатьтән азат –
Байлыгым юк мирас итәрлек.

Васыять язмасам да, сезгә калыр
Җан җырларым – күңел байлыгым.
Язылмаганнарын калдыралмам,
Үзем белән бергә алырмын.

Сезгә калыр сандугачлы таңнар,
Кояшлы көн, айлы төн яме.
Бабайлардан калган туган җирне,
Васыятьнамә язып тормый гына,
Исәннәргә мирас итәмен...

Табылмаган малым таулар булып
Кала сезгә өемнәре белән,
Янә кала таудай мәшәкатьләр,
Чишелмәгән төеннәре белән...

Бер гомергә болар баштан ашкан,
Риза булып кабул кыл гына.
Килер бер көн:
Сез дә бу байлыкны,
Васыятьнамә язып тормый гына,
Тапшырырсыз яңа буынга...

МИН БИТ ЗАТЛЫ БЕР АЛМАГАЧ ИДЕМ...

Мин бит затлы бер алмагач идем,
Алмаларның биреп татлысын,
Кешеләр, сезне сыйламакчы идем, –
Җимешләрем нигә ачы соң?

Тормыш бакчасында ни җитмәде? –
Тәрбияләү, карау җитмәде.
Ә шулай да җимеш биргән чакта,
Күпләр мине урап үтмәде.

Ачырак һәм ваграк булсалар да,
Җимешләрем алар яратты.
Татлысы да аның, ачысы да
Бу дөньяга бердәй ярашлы.

Мин хуҗасыз калган бакчаныкы...
Зарланырга ләкин соң инде.
Җимешемне җыйган узгынчылар
Ботарлады мине, сындырды...

Кыргый алмагачка әйләндем мин,
Ачы язмышыма түземле.
Көзен койган яфракларым белән
Тамырларым ашлыйм үземнең.

Ә кемнәрдер хәзер, йөзен чытып:
«Җимешләре ачы...» – димешләр.
Белмиләрме, нинди булсалар да,
Болар – безнең уртак җимешләр.

Ботакларым ботарласалар да,
Тамырларым, шөкер, сау әле.
Ачырак һәм ваграк булсалар да,
Җимеш бирер җаем бар әле.

ӘЛМӘНДӘР

Шәүкәт Биктимеровка

Кордашларның күбесе дөньяда юк,
Хәмдебанулар да картайган,
Әлдермешнең Әлмәндәре генә
Картаюны белми, яшь һаман.

Казан урамыннан узган чакта,
Һәркем карый аңа сокланып.
«Саумы, Әлмәндәр абзый?» –
дигәннәргә:
«Аумыйм әле», – ди ул, шукланып.

Шатлык-кайгыларың уртаклашыр,
Күңел күтәрерлек сүз табып.
Балаларның башларыннан сыйпар,
Ә кызларга карар мутланып.

Мутланмыйча!
Әле абзагызда
Өйләнергә дигән уй һаман.
Тик шунысы начар:
Аңа дигәннәре картайганнар,
Яшьрәкләре әле... тумаган.

Чурту матыр!
Боегуны белмәс,
Коеп куйган татар карты бу.
Юк ла, татар карты гына түгел,
Көчле рухлы татар халкы бу!

Шуңа һәркем соклана бит аның
Шан-шәүкәтле җаны көченә.
Ничек сокланмыйсың
Фани бу дөньяда
Газраилне җиңгән Кешегә?!

МӘКАМ

Нәфис сүз тылсымчысы, сәхнәбез
йолдызы Айрат абый Арслановка

Чү!
Тәүге кат кайчан ишеттем соң
Бу сәмави, моңлы мәкамне?
Әниемнең бишек җырыннанмы,
Догасыннан микән әткәмнең?

Шагыйрь гамен, туган халкым диеп
Януларын, көрәш җегәрен
Ачык тойдым,
Тыңлаганда аның
Мәкам белән шигырь сөйләвен.

Тарих дәрьясының төпкеленнән
Күңелләргә кага һәр сүзе.
Бу хисләрне әллә шагыйрь белән
Кичергәнме икән ул үзе?
Кичергәндер...
Ул да, Йосыф кебек,
Зөләйхага гашыйк булгандыр.
Тукай белән, Җәлил белән бергә
Өзгәндер дә коллык богавын,
Давылларны ярып очкандыр ул,
Ирек даулау өчен
Бүгенгә,
Көрәшләрдә шәһит булганнарны
Терелтергә безнең күңелдә...
Ходай аңа затлы мәкам биргән,
Ачкычларын – сүзләр серенең.
Шул мәкамнең нуры-яктылыгы
Күрсәтә күк бөтен затлылыгын
Һәм җегәрен татар теленең.

ГЫЙБРӘТ АЛЫЙМ ДИСӘҢ...

С.-ка

I

Балачакта әти-әни кирәк,
Кирәк була өлкән туганнар.
Алар һаман кирәк,
Ләкин ул хисләргә
Төзәтмәләр кертә Вакыт-узаман.

Кем уйлаган, «Әзи, әзи!» диеп,
Минем арттан чапкан бу малай,
Казан урамында куып тотып,
Мине узар диеп берзаман.
Узу кирәк, –
Карт агачлар кайчак
Яшьрәкләргә ясый күләгә.
Кала инде безгә – өлкәннәргә –
Сезгә күбрәк якты теләргә.

Тик онытмыйк,
Кирәк күләгә дә
Эссе җәйдә, салкын кышларда.
Куе ябалдашлы зур агачка
Оя кора ласа кошлар да.

Бу дөньяда гыйбрәт алыйм дисәң,
Табигатьне күзәт иң башта.
Һәрбер куак, һәрбер чәчкә анда,
Бер-берсенә комачауламыйча,
Бергә-бергә үрелә Кояшка...

II

Бәйрәм алларыннан ташпулатлар
Яктыралар яңа буяудан.
Вакыт уза,
Һәрни тузган кебек,
Буяулар да уңа берзаман.

Җил уңдыра, яңгыр суы юа, –
Бина кала, бина бирешми.
Безгә, энем, кешегә җылы биргән
Бина кебек булу тиешле.

Бәйрәмнәрдә булган мактауларга
Матур буяу диеп карыйм мин.
Шуңа хәтеремнән торып-торып
Миңа ныклы бина була алырлык,
Туганнарым, сезне барлыймын.

Бу дөньяда гыйбрәт алыйм дисәң,
Үз җаныңа күз сал иң башта.
Ятлар белән дөнья куганда да,
Алар белән җиңел булганда да,
Туганнарың юлда югалтма!

Күршеләр татар эзен юкка чыгармакчы

Башкортстан хакимияте Чишмә районында Евразиянең күчмә халыклар цивилизациясе музее төзергә ниятли. Тарихчылар моңа каршы, чөнки биредә Алтын Урда чорына караган татар археология һәйкәлләре саклана.

Башкортстан татарларын башкортлаштыру сәясәте турында күп язылды. Күрше республика хакимиятенең татарларны – башкорт, татар телен башкорт теленең диалекты итеп күрсәтергә тырышуына шулкадәр ияләштек ки, бу зәхмәтнең нәтиҗә бирәсенә татарлар гына түгел, башкортлар үзләре дә ышанмый башлады, ахры. Ләкин тик торырга ярамый,ниндидер яңа «могез чыгарырга» кирәк. Хәзер күршедәге сәясәтчеләр татарның тарихына кул сузып маташа.

Декабрь башында Уфада Башкортстан башлыгы администрациясе җитәкчесенең урынбасары Урал Килсенбаев катнашында «Урта гасырларда Евразиянең күчмә халыклар цивилизациясе» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Аның төп темасы татар археология һәйкәлләре саклана торган Чишмә районында Евразиянең күчмә халыклар цивилизациясе музее төзү турында фикер алышу булган. Конференциядә Казаннан Халитов исемендәге Археология институты директоры Айрат Ситдиков белән институтның фәнни хезмәткәре, күренекле археолог Фаяз Хуҗин да катнашкан. Татар археологларының Уфага баруы Татарстан тарихчылары арасында зур ризасызлык уяткан.

Чишмә районында күчмә цивилизацияләр музее салу татарларга нинди зыян китерә?

Башкортстанның Чишмә районында Алтын Урда чорына караган татар археология һәйкәлләре – Тура-хан, Хөсәен бәк төрбәләре (русча – мавзолей), каберлекләр, кабер ташлары саклана. Нәкъ шундый тарихи һәйкәлләр Болгар шәһәрчегендә дә бар. Тарихчыларның сүзләренчә, әлеге каберлекләр хәзерге Чишмә районында урта гасырларда татарлар, утрак тормыш алып баручы мөселманнар яшәвен дәлилли. Күчмә халыкларның каберлекләре бөтенләй башка төрле. Белгәнебезчә, башкортлар XVIII гасыр уртасына кадәр күчмә халык булган.

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты хезмәткәре, тарих фәннәре докторы Искәндәр Измайлов урта гасырларда Башкортстанның төньяк-көнбатышында яшәгән татарлар турында болай сөйли:

«Идел буе Болгар дәүләте (X-XIII гасырлар) халкы Чишмә елгасының көнбатыш ягында яши, көнчыгышка таба китми. Байтак вакыт узгач, Алтын Урда чорында (XIII-XV гасырлар) бу

утрак халык, икмәк җитештерүне арттыру өчен, актив рәвештә көнчыгышка таба күчә башлап, Агыйдел елгасына кадәр территорияне, шул исәптән Уфа тирәсен биләп ала. Бу – шактый алга киткән, бай халык була. Алар яшәгән чордан каберлекләр, төрбәләр, татар телендә язылган кабер ташлары сакланып калган.

Алтын Урда таркалгач, калмык, ойрот кебек халыклар һөҗүм итеп тору сәбәпле, яңа җирләрдә яшәү тынычсыз була башлый, андагы халык Кама елгасына таба күченә. XIV гасырга караган археология һәйкәлләренә күз салсак, җир эшкәртүче мөселман халкы Агыйдел елгасы бассейнын биләгәнен, ә күчмә халыклар күпкә көньяктарак йөргәнен күрәбез. Мәсәлән, Көньяк Уралда курганнар саклана.

Агыйдел елгасы бассейны территориясе Россия дәүләте карамагына күчкәч, ягъни XVI-XVII гасырларда, бу җирләрнең көнчыгыш өлешенә көньяктан күчмә кабиләләр килеп утыра. Россия дәүләте аларны башкортлар дип атый.

Чишмә районындагы төрбәләрне беркайчан да башкорт төрбәләре дип ишеткән юк иде. Аны заманында Уфа археологлары да тикшерде. Ул төрбәләр Болгар шәһәрчегендә булган тарихи һәйкәлләрдән аерылмый. Аларда күчмә халыкларга хас үзенчәлекләр юк, ә күчмә халыкларның тарихи эзләре утрак тормыш алып барган халыкларныкыннан бик нык аерыла.

Хәзер Башкортстан хакимияте республика территориясендә булган бөтен археология һәйкәлләрен башкортныкы итеп танытырга тырыша. Бу – урта гасыр һәйкәлләренә дә, тимер гасыр чорыныкына да кагыла. Алай эшләгәнче, алар башта «урта гасырлар чоры башкорты» дигән төшенчәне аңлатсын иде. Сәясәтчеләр моның белән мәшәкатьләнеп тормый шул. Алар, сәяси технологияләр белән шөгыльләнеп, фактларны бутый да, җәмәгатьчелек алдына «күчмә халыклар цивилизациясе музее төзибез» дигән «ачыш» китереп куя. Ни өчен утрак тормыш алып барган мөселман халыклары калдырган һәйкәлләр кинәт күчмә халыкларныкына әверелә? Алар аны аңлатырга теләми. Бу – бары тик сәясәт. Моның фәнгә катнашы юк.

Бу уңайдан тагын бер кызыклы мәгълүмат бар. Тау итәгендә бронза гасырга караган каберлек табылды. Чиләбе өлкәсендә дә шул чорның Аркаим каберлеге бар. Башкортстан сәясәтчеләре аларны да башкорт мирасы дип танытырга тели. Янәсе, бронза гасырдан бирле яшәгән мифик башкортлар шәһәрләр, цивилизацияләр төзегән. Монда милли миф чыгару мисалы ачык күренә. Миф никадәр абсурд булса да, аңа ышандыру җиңел, чөнки аны фәнни яктан исбатлап торасы юк.

Ни өчен сәясәтчеләр борынгы заманнарга керә, дигән сорау туа. Бу «Урал Батыр» эпосын аклау өчен кирәктер. «Урал Батыр» эпосының XX гасыр уртасында уйлап чыгарылган әсәр икәне ачыклана бара. Узган гасырда эпослар белән мавыгу модасы бар иде. Аңарчы бер җирдә дә күренмәгән, таралмаган әсәр, тәмәке савытыннан атылып чыккан шайтан кебек, кинәт юктан бар булды.

2016 елда Тарих институты чыгарган «История татар западного Приуралья» дип аталган монографиядә Уфа археологы Геннадий Гарустовичның Чишмә районындагы төрбәләр турында мәкаләсе бар. Ул Тура-хан белән Хөсәен бәкнең төрбәләрен Болгар осталары төзүе турында яза. Галим сүзләренчә, Хөсәен бәк төрбәсе тулысынча Болгар архитектурасын кабатлый. Төрбәнең гөмбәзеннән алынган материалның анализы ташларның Болгардан китерелгәнен күрсәткән.

Башкортстанда туып үскән

эпиграфика белгече, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галиме Венер Усманов Чишмә районындагы кабер ташларын өйрәнеп чыккан. Ул аларны «Идел буе Болгар дәүләте мирасы» дип исәпли.

– Күчмә халыклар музеен Идел буе Болгар дәүләтенә кергән Чишмә районы җирләрендә түгел, ә Башкортстанның көньяк районнарында – далада салу кулайрак булыр иде. XVII гасырда монда Нугай Урдасының төрки кабиләләре яшәгән. Башкорт халкының 50 проценты – нугай татарлары токымы. Бу турыда башкорт тарихчылары белә. Мин үзем дә өлешчә юрматы «башкорты», – диде В.Усманов.

Тарихчы, җәмәгать эшлеклесе Илнар Гарифуллин фикеренчә, Башкортстан хакимияте күчмә халыклар цивилизациясе музее ярдәмендә татарның тарихи мирасын үзләштереп, республиканың төньяк-көнбатышында «борынгыдан бирле» башкортлар яшәгән, ә татарлар бирегә XVIII-XIX гасырларда гына күченеп килгән, дип күрсәтергә тели. Шул рәвешле татарның борынгы эзләрен югалту эше бара.

– Чынлыкта, Уфага кадәрле җирләр, шул исәптән Чишмә районы да, Алтын Урда чорыннан ук татарлар җире булган, – ди И.Гарифуллин. – Казан ханлыгы чорында бу территория ханлыкның Агыйдел олысына кергән. Рус елъязмаларында ул җирләр «Беловолжская земля» дип аталган. Башкортстанда татарларның аннан башка да тарихи эзләре бар. Мәсәлән, Чакмагыш районында Калатау шәһәрчеге. Андый атамалы урыннар Татарстанда да бар.

Музей төзү проектын Бөтендөнья башкортлар корылтае рәисе Юлдаш Йосыпов алга сөрә. Ул – татарны башкортлаштыру сәясәте идеологларының берсе. Аларның максаты – татарның тарихи эзен юкка чыгару. Ягъни, алар монда яшәгән татарларны башкорт булган дип күрсәтергә тырыша. Ул – татарларга каршы проект. Бу җирләрдә күчмә халыклар йөрмәгән, чөнки Оренбург, Казахстан кебек, күчмә тормыш алып бару өчен уңайлы җир түгел бу. Күчмә халыклар яшәмәгән җирдә күчмә халыклар цивилизациясе музее ачу фәнни яктан сәер тоела.

Музей төзелерме, юкмы, дигән сорауга, И.Гарифуллин: «Нәтиҗә финанс мәсьәләсе хәл ителүдән һәм фәнни җәмәгатьчелек бу проектны хуплаудан тора, – дип җавап бирде. – Аңа каршы фикерләр күбрәк булса, төзелмәячәк. Башкортстанда да аны хупламаучылар, кирәкмәгәнгә акча сарыф итү дип исәпләүче журналистлар, блогерлар бар», – диде ул.

Татарстан археологларының Уфада узган конференциядә катнашуы тарихчыларда ризасызлык тудыруын билгеләп үткән идек. Шул сәбәпле, Археология институтының фәнни хезмәткәре Фаяз Хуҗинны да тыңладык.

– Мин сәясәт, башкортлар белән кызыксынганым юк, – ди ул. – Башкортстанга баргач, күрдем инде: алар үз тарихларын нык ярата, мәдәниятләрен үстерү турында безгә караганда күбрәк кайгырта, дигән фикердә калдым. Безгә алардан өйрәнергә кирәк.

Пленар утырышның азагында Евразиянең күчмә халыклар цивилизациясе музее турында бер доклад булды. Ул фәнни чыгыш түгел иде, мәдәни һәм тарихи мирасны саклау буенча бер белгеч тарафыннан укылды. Музей проектының архитектурасы, юллар салу турында сүз барды. Фәнни концепция читтә калды.

Күчмә цивилизация нәрсә дигән сүз? Бер урыннан икенче урынга күчеп йөргән халык цивилизация төзи аламы? Шәһәрләре, дәүләтләре юк. Цивилизация дигәч, күз алдына, беренче чиратта, шәһәрләр, дәүләтләр, шәһәр архитектурасы, язмачылык килеп баса. «Цивилизация» сүзен куллану дөресме икән? Шушы мәсьәлә буенча галимнәр арасында кулуарларда гына сөйләшүләр булды. Без «күчмә халыклар цивилизациясе» дигән атама дөрес түгел, дигән фикергә килдек.

Секция утырышларының берсендә мин күренекле башкорт археологы Нияз Мәҗитовның Болгар археологиясе буенча фикерләре турында чыгыш ясадым. Соңгы елларда ул Болгар археологиясенә дә кысыла башлады. Археолог буларак, аның фикерләре белән килешә алмыйм. Чыгышымда шуны әйттем.

Н.Мәҗитовның Башкортстан археологиясенә керткән өлеше искиткеч зур, чөнки ул борынгы тарихны ныклап өйрәнде, музейга бик күп экспонатлар туплады. Ул мирас югалмый, аны бүгенге буын археологлар да өйрәнә. Шул ук вакытта, Мәҗитовның әлеге чыганакларга нигезләнеп әйтелгән бөтен фикерләре белән дә килешеп булмый. Әгәр музейны Мәҗитов концепциясенә нигезләнеп эшләсәләр (ә ул шулай бара), башкорт тарихы Татарстанның яртысын – Биләргә кадәрле территорияне – колачлап аларга тиеш була. Бу – дөрес түгел.

Тагын алар «Уфа территориясендә борынгы башкорт шәһәрләре булган» дигән теорияне алга сөрә, мин моңа да каршы килдем. Борынгы шәһәрләр булган, ләкин алар башкорт тарихы белән бәйләнмәгән. Тикшеренүләр күрсәткәнчә «Уфа–2» дип аталган шәһәр V гасырда төзелә башлый да IX гасырда җимерелә. Шул чордан соң анда озак дәвер бушлык була. Бу шәһәрне башкортларның борынгы бабалары түгел, ә венгрлар төзегән. Алар – бөтенләй икенче төрле халык. Борынгы угырлар, ягъни венгрлар Башкортстан территориясендә күп мирас калдырган. Дөнья фәнендә бу мәсьәлә буенча шундый төпле фикер урнашкан, ә Мәҗитов «алар угырлар түгел, төрки телле халыклар» дигән теорияне исбатламакчы булды. Мин үз докладымда, сәясәтне кертмичә, бу мәсьәләне кабат бергәләп өйрәнергә кирәк, дигән фикер әйттем. Башкортлар минем фикерләр белән килешеп бетмәсә дә, миңа каршы чыгучы булмады.

Нәтиҗә.

Әлбәттә, башкортлар үз тарихларын ярата, мәдәниятләрен үстерүгә зур көч куя, ләкин татарларның теле, мирасы хисабына милли мәнфәгатьләрне кайгырту ихтирамга лаек түгел. «Кешенекенә тимә, үзеңнекен бирмә» дигән гыйбарә юкка гына халык теленә кермәгән. Ут күршеләребезнең ялганга, татарларны «кысуга» корылган пропагандасы киләчәктә тискәре нәтиҗәгә китермәсме? Татар бит ул – тарихта эзле халык. Төтен таралгач, бүгенге сәясәтчеләр нәрсә дип акланырлар? Монда җавапларга караганда сораулар күбрәк туа.

Рифат КАЮМОВ.
intertat.tatar

Шагыйрь рухы шатмы?

Туган телебезгә тупас басым
Булачагын белгән булсалар,
Үзе теләп дошман
каршысына
Китәр иде микән Мусалар?!
Илдус Гыйләҗев,
гыйнвар, 2018 ел.

Шагыйрьнең иң соңгы шигырьләренең берсе бу. Арабыздан китәренә ике айлап кына калганда да, туган тел турында исәннәргә әйтеп калырга тиешле саный ул. Исәннәргә шагыйрь васыяте...

Азнакай районы мәктәпләрендә гомере буе татар теле һәм әдәбияты фәнен укыткан Флёра Миндубаева шагыйрьне болай дип искә ала:

Ул да Туфан Миңнуллин, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиевләр кебек җаны-тәне белән татар телен яратучы, аны якларга, сакларга тырышучы шагыйрьләрнең берсе иде.

Дәүләт Советы депутаты Марат Әхмәтов та шагыйрь иҗатына битараф булмады. «Илдус Гыйләҗев: Яшәү – сөю!» (2020 ел) дип аталган истәлекләр китабына кереш сүздә ул болай дип яза: «Илдус Сабир улы гомер буе авылда, саф чишмә кебек челтерәгән үз теле мохитендә яшәде, халкына хезмәт итте. Шуңа да аның шигырьләреннән бураннар җылылыгы, яңа сауган сөт исе бөркелә. Азнакай ягы авылларының матурлыгын Илдус Сабир улы шигъри сурәтләр аша күңел кылларыбызны тибрәндерерлек, туң йөрәкләрне дә эретерлек, туган яклардан киткәннәрне үкенеп елатырлык итеп сурәтли.

Тормыш гел үзгәрештә. Бүген хуҗалык итү мәсьәләләре янына милләтебезне, туган телне, авылларны саклау ихтыяҗы килеп басты. Илдус Сабир улы исә иҗат корабын шул юнәлешкә борды, татар авыллары тарихын туплады, үзеннән соң бай хәзинә калдырды».

И. Гыйләҗевнең авыл хуҗалыгы өлкәсендәге хезмәтләре югары бәяләнде – ул СССР Министрлар Советы премиясенә лаек булды. Ә шигърият өлкәсендә? Язучы Фәүзия Бәйрәмованың бер радиода «Гаделлекне үзебездән башлыйк» темасына ясаган чыгышы гыйбрәтле:

«Казаннан, Татарстаннан читтә яшәүчеләр Тукай бүләге турында хыяллана да алмый. Азнакайдан талантлы шагыйрь Илдус Гыйләҗев, Әлмәттән Разим Вәлиуллин, титаник хезмәт – «Миллият сүзлеге» язган Адлер Тимергалин, дөньялар гизеп, татарлар турында дөнья хәтле әсәрләр язып калдырган Тәүфыйк Әйди һәм тагын бик күпләр бу дан-дәрәҗәләрне күрмичә, милләттән һәм дәүләттән рәхмәт ишетмичә, бакыйлыкка күчте. Бәлки аларның да күңелләрендә бу гаделсезлеккә карата рәнҗү калгандыр».

Илдус Гыйләҗевнең вакытсыз арабыздан китүен ишетү белән, шул ук көнне, беренчеләрдән булып, каләмдәше, Лениногорск районында яшәп иҗат итүче танылган шагыйрь Таһир Шәмсуаров аңа багышлап шигырь иҗат итте:

Ул юк дигән авыр хәбәр
Йөрәкне телеп үтте.
Бәхәссез талант иясе
Бәясен алмый китте...

Шагыйрь исән чакта, аның иҗатына йомгак ясап, фәнни югарылыкта җентекле анализ ясаучы һәм бәя бирүче Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров булды. Ул И. Гыйләҗевнең «Ихлас тойгылар» (2016) китабында шагыйрь иҗаты турында 20 битлек язма чыгарды. Андагы кайбер юлларга күз салыйк:

«...Аның шигырьләре бүтән беркемнеке белән дә буталмый, хәтта имзасыз чыгарылган очракта да, аларны кем язганын бик күпләр белеп алачак…

…Үз җанында милләт гамен йөрткән И.Гыйләҗев шагыйрьлекне билгели торган кагыйдәне дә күрсәтеп үтә:

Матур шигырь языйм дисәң,
Бармакларың сөйсен каләм.
Кешеләрне ярата бел,
Йөрәгеңә сыйсын галәм!»

2019 елның 22 гыйнварында Туйкә авылында И.Гыйләҗев истәлегенә такта ачу тантаналарында да З.Мансуров тирән эчтәлекле чыгыш ясады.

Шагыйрьнең вафатына да 5 ел. Матбугат битләрендә аның исемен мәңгеләштерү, музеен булдыру кирәклеге турында да кузгатылган иде. Билгеле булганча, И.Гыйләҗевнең Татарстан китап нәшриятына исән чакта үз кулы белән тапшырган «Хакыйкать чаткылары» исемле соңгы китабы басылмый ята. Татарстан Язучылар берлеге дә моңа битараф булмасын иде.

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ,
Азнакай.

Вакыйга

Антон ЧЕХОВ

Иртәнге як. Тәрәзә пыялаларын бизәгән боз челтәрләре аша балалар бүлмәсенә якты кояш төшә. Кыска чәчле түймә борынлы, алты яшьләрендәге Ваня атлы малай белән аның бөдрә чәчле, тулы тәнле, яшенә караганда кечерәк күренә торган дүрт яшьлек сеңлесе Нина уяналар да ачуланып карават челтәре аша бер-берсенә карашалар.

– А-ай, оятсызлар! – дип сукрана балаларның нянялары. – Юньле кешеләр йокыларыннан торып чәй эчте инде, ә сез әле һаман йокы симертәсез...

Кояш нурлары келәм өстендә, стеналарда, няняның күлмәк итәкләрендә шаярлар һәм балаларны үзләре белән бергә уйнарга чакыралар кебек, ә балалар аларны искәрми дә. Алар кәефсезләнеп уянды. Нина иреннәрен турсайтты да чыраен сытты.

– Няня, чә-әй! – дип көйсезләнде ул.

Ваня, маңгайларын җыергалап, еларга ниндирәк сәбәп табарга икән дип уйланды. Күзләрен чет-чет йомгалап авызын гына ачкан иде, нәкъ шул вакытта кунак бүлмәсеннән әнисенең тавышы ишетелде:

– Песигә сөт бирергә онытмагыз, – аның хәзер балалары бар!

Ваня белән Нина борыннарын сузып аптырашып бер-берсенә караштылар, аннары икесе берьюлы кычкырып җибәрде, караватларыннан сикерешеп төштеләр дә, чинашып, яланаяк, күлмәкчән килеш кенә кухняга йөгерделәр.

– Песи балалаган! Песи балалаган! – дип чыр-чу килде алар.

Кухнядагы эскәмия астында бәләкәйрәк кенә бер тартма тора, камин яккан чакларда ул тартма белән Степан күмер ташый. Ә хәзер тартмадан песи карап тора иде. Аның соры йөзендә чиксез арыганлык сизелә, сызык кына каралы яшел күзләре хисләнеп, әсәрләнеп карый... Ул мияулаумакчы булып, авызын киң итеп ача, ләкин аның тамак төбеннән ысылдаган тавыш кына чыга. Песи балаларының чыелдаганы ишетелә.

Ваня белән Нина тартма каршысына чүгәлиләр дә тын да алмыйча песигә карап утыралар... Алар шулхәтле гаҗәпләнгәннәр, няняның сукрануын да ишетмиләр. Икесенең дә ихлас сөенечтән күзләре ут яна.

Балаларны тәрбияләү эшендә һәм балалар тормышында йорт хайваннары әллә ни зур булмаса да, шулай да уңай роль уйный. Үзләре көчле, үзләре юаш этләрне, әрәмтамак болонкаларны, тоткынлыкта үлгән кошларны, аңгыра булсалар да, яман да һавалы күркәләрне, кызык өчен генә койрыкларына басып газапласаң да кинә сакламаган акыллы карт песиләрне кайсыбыз хәтерләми? Чандыр гәүдәле, чырайсыз Карл Карловичның үгет-нәсихәтләренә, суның кислород белән водородтан гыйбарәт икәнен исбатларга маташа торган гувернантканың фәлсәфә сатуларына караганда, өебездәге җан ияләренең чыдамлыгы, тугрылыклыгы, бөтен рәнҗетүләребезне дә кичерә алу сәләте баланың акылына ныграк тәэсир итәдер сыман тоела миңа.

Нина күзләрен зур итеп ачып челтер-челтер көлә:

– Ай, нинди бәләкәйләр! Үзләре гел тычкан төсле! – ди ул.

– Берәү, икәү, өчәү...– дип саный Ваня. – Өч песи баласы. Димәк, миңа – берсе, сиңа – берсе, тагын берәрсенә – берсе.

Үзенә игътибар итүләренә куанып, песи:

– Мрр... Ммрр...– дип мырлый.

Песи балаларын күреп туйгач, балалар аларны песи астыннан алып, куллары белән әвәләргә тотыналар, аннары, аның белән дә канәгать булмыйча, күлмәк итәкләренә салалар да йөгерешеп бүтән бүлмәләргә алып чыгып китәләр.

– Әнием, песи балалаган! – дип чыр-чу киләләр.

Әниләре кунак бүлмәсендә ниндидер бер таныш булмаган әфәнде белән сөйләшеп утыра. Юынмаган, киенмәгән, күлмәк итәкләре күтәрелгән балаларын күргәч, ул уңайсызлана, аның күзләрендә ачулы очкыннар чагыла.

– Төшерегез күлмәгегезне, оятсызлар! – ди ул, – Чыгып китегез моннан, югыйсә хәзер кирәгегезне бирәм.

Балалар әниләренең янавын да ишетми, чит кеше булуын да искәрмиләр. Алар песи балаларын келәмгә салалар да колак тондыргыч тавыш куптаралар. Песи балалары тирәсендә ялварып әниләре мыраулый.

Бераздан балаларны үз бүлмәләренә алып кереп киендерәләр, гыйбадәт кылдырып чәй эчерәләр. Бу кызыксыз эшләреннән арынуга инде алар дәртләнеп яңадан кухняга торып чабарга әзер.

Гадәттәге шөгыльләр, көндәлек уеннар иң арткы планга күчте.

Песи балалары дөньяга килүләре белән бөтен нәрсәне оныттырдылар, дөньяның кендегенә әйләнделәр. Әгәр дә мәгәр Ваняга яисә Нинага һәр песи баласы урынына бер пот конфет йә булмаса меңәр данә ун тиенлек тәкъдим итсәләр дә, алар моны һич тә икеләнмичә кире кагар иде. Няня белән кухарканың теш-тырнагы белән каршы торуына да карамастан, төшке аш җиткәнче, балалар кухнядан чыкмый, дөньяларын онытып, песи балалары яткан тартма янында кайнашалар. Кыяфәтләре җитди үзләренең, песи балаларын киләчәктә нишләтергә дигән мәсьәләне хәл итеп азапланалар: песи баласының берсе, карт әнисен юатып тору өчен, аның янында өйдә кала, берсе дачага бара, тагын берсе базда яши, чөнки анда күсе-тычкан бик күп.

– Ә нигә күрми-карамый соң алар? – дип аптырый Нина. – Хәерчеләрнеке кебек аларның да күзләре сукыр.

Ваняны да борчый бу мәсьәлә. Ул бер песи баласының күзен ачарга тырышып, борынын тарта-тарта бик озак мыштырдый, әмма аның бу маташуы барып чыкмый. Песи балаларының ит белән сөттән баш тартулары да бик сәер тоела. Аларның бәләкәй борын төпләренә китереп куйган бөтен нәрсәне шундук соры йонлы әниләре ялмап ала.

– Әйдә песи балаларына өй салабыз, – дигән тәкъдим кертә Ваня.– Алар өчесе өч өйдә яшәрләр, әниләре алар янына кунакка йөрер...

Кухняның төрле почмакларына эшләпә сала торган катыргы тартмалар куялар. Шул тартмаларга песи балалары кереп урнаша. Әмма гаиләне болай бүлгәләргә әле иртәрәк, песи инәлүле, әсәрләнүле кыяфәт белән бөтен тартмаларны әйләнеп чыга да балаларын элекке урыннарына ташып куя.

– Әниләре – песи, әтиләре кем соң аларның? – дип кызыксына Ваня.

– Әйе, әтиләре кем соң аларның? –дип кабатлый Нина.

– Әтисез ярамый инде.

Ваня белән Нина бик озаклап песи балаларының әтисе кем буласын уйлашалар, ахыр чиктә баскыч астындагы кладовойда ташландык уенчыклар арасында аунап яткан, койрыгы өзелгән кызгылт атка тукталалар. Уенчык атны кладовойдан алып кереп, тартма янына бастырып куялар.

– Кара аны, шушында гына тор, песиләрең тәртип бозмасын! – дип боера балалар бахбайга.

Боларның барысы да үтә дә җитди кыяфәт белән әйтелә һәм шундый ук җитди кыяфәт белән эшләнә дә. Нина белән Ваня песи балалары салынган тартма яныннан китмиләр. Куанычларының чиге юк. Ләкин аларга бик авыр, бик газаплы минутлар да кичерергә туры килә.

Төшке аш алдыннан Ваня әтисенең кабинетында мөкиббән китеп өстәлгә карап утыра. Лампа янындагы герблы кәгазь өстендә песи баласы кыймыл-камыл килә. Ваня аның кыймылдаганын йотылып карап утыра һәм ара-тирә песи баласының йөзенә йә каләм, йә шырпы белән төртеп карый... Кинәт, җир астыннан калкып чыккандай, өстәл буенда Ваняның әтисе пәйда була.

– Бу ни бу? – дип сорый ул ачуланып.

– Бу... бу – песи баласы, әтием...

– Менә күрсәтермен мин сиңа песи баласын! Күр әле нишләгәнсең, юньсез малай! Бөтен кәгазьләремне пычратып бетергәнсең бит!

Ваняны тәмам аптырашта калдырып, әтисе аның песи баласын яратуын хупламый, хәйран калып сөенәсе урында, ул Ваняның колагын бора һәм:

– Степан, алып кит бу җирәнгечне! – дип кычкыра.

Төшке аш вакытында да тавыш чыга... Бер заманны барысы да ашап утырган бер мәлне кинәт чыелдаган тавыш ишетелә. Тавышның каян килгәнен эзли башласалар – Нинаның алъяпкычы астыннан песи баласы килеп чыга.

– Кит хәзер үк өстәл яныннан! – дип кычкыра әтисе Нинага, – Хәзер үк чүплек базына ташлагыз песи балаларын! Эзе булмасын шул нәҗесләрнең!

Ваня белән Нинаның котлары оча. Песи балаларын чүплек базында үтерү үзе бер кансызлык булса, песи белән агач атның балаларын тартып алу – икенче бер рәхимсезлек, аннары бит әле тартма да буш кала, киләчәккә планнар җимерелә, – ә ул матур киләчәктә песи баласының берсе үзенең карт әнисен юатырга тиеш иде, икенчесе – дачада яшәр, өченчесе базда күсе тотар иде... Балалар елашырга, песи балаларын кызганыгыз дип ялварырга керештеләр, әтиләре риза булды, ләкин бер шарт куйды – балалар кухняга кермәсен, песи балаларын тотмасын.

Төштән соң Ваня белән Нина әле бер бүлмәгә, әле икенчесенә кереп зарыгышып йөрделәр. Кухняга керергә ярамый дигән сүз аларның күңелен тәмам боектырды. Алар тәм-том ашаудан да баш тартты, көйсезләнделәр, әниләре белән дорфа сөйләштеләр. Кичен Петруша абзалары килгәч, аны бер читкә алып китеп, песи балаларын чүплек базына ташларга кушкан әтиләреннән зарландылар.

– Петруша абый, әнигә әйт әле, песи балаларын безнең бүлмәгә куйдыртсын әле, – дип ялынды алар. – Әйт инде, ә?

– Ярар, ярар, әйтермен! – дип кул гына селтәде абзалары.

Петруша абзалары гадәттә үзе генә килми. Аның белән бергә зур гәүдәле, Неро атлы кара эт ияреп килә. Төп чыгышы Дания дигән илдән аның. Салынкы колаклы, таяк кебек каты койрыклы ул. Эре кыяфәтле бу эт тын гына, моңсу гына басып тора; балаларга ул әйләнеп тә карамый, яннарыннан үтеп барганда да, урындыкка бәргән сыман, аларга койрыгы белән бәреп үтә. Балалар аны җаны-тәннәре белән күралмый, әмма бу юлы аны үз кирәкләренә файдалану мөмкинлеге нәфрәт хисеннән өстенрәк булып чыга.

– Нина, әйтимме бер нәрсә? – ди Ваня күзләрен зур итеп ача. – Ат урынына Неро әти булсын! Ат бит ул тере түгел, Неро – тере!

Кич буе алар әтиләренең винт уйнарга утыруын көттеләр, аннары Нероны сиздермичә генә кухняга уздырырга мөмкин булачак... Менә, ниһаять, әти кеше кәрт уйнарга утыра, әниләре самавыр тирәсендә кайнаша, балаларның нишләгәнен искәрми... Бәхетле минутлар җитә.

– Киттек! – дип пышылдый Ваня сеңлесенә.

Әмма шушы вакытта Степан килеп керә дә көлә-көлә хәбәр сала.

– Байбикә ханым, Неро песи балаларын ашады!

Нина белән Ваня агарынып, өнсез калып Степанга карый.

– Валлаһи дип әйтәм! – дип көлә Степан, – тартма янына килде һәм капты да йотты.

Өйдә булган бөтен кеше дәррәү кубып, явыз Нерога ташланыр кебек тоелды балаларга. Ләкин кешеләр тыныч кына утыра бирделәр, алар бары тик алып хәтле этнең аппетитына гына сокланды. Әтиләре белән әниләре дә көлештеләр... Неро исә өстәл буенда койрыгын болгап йөри һәм бик канәгать булып авыз-борынын ялый иде... Бер песи генә тынычсызлана, койрыгын сузып бүлмәдән бүлмәгә йөри, шикләнеп кешеләргә карый һәм кызганыч итеп мияулый иде.

– Балалар, сәгать унынчы! Йокларга вакыт! – дип кычкыра балаларның әниләре.

Ваня белән Нина йокларга ята, үзләре елый. Рәнҗетелгән песи һәм кансыз, миһербансыз, тиешле җәзасын алмаган Неро турында уйлый алар.

С.ИБРАҺИМОВА тәрҗемәсе.

(Дәвамы. Башы 1 нче санда).

Азнакай авылы

Сәүдәгәрләрнең икенчесе – Хәсәнша Баязитов (25 яшь). Ул үзенең һәм абыйсының гаиләсе белән бер хуҗалык булып яши. Әлбәттә, һәрберсенең монда зур йортлары була. Баязитовларның хуҗалыгы сәүдәгәрләр арасында гына түгел, гомумән, Азнакайда иң эре хуҗалык санала. Аларның сатып алган җир участогының 164,5 дисәтинәсен – сөрүлекләр, 8 дисәтинәсен – печәнлекләр һәм 9 дисәтинәсен урман алып тора. Калган 43,5 дисәтинә җир эшкәртелми, шуның 7 дисәтинәсен алар арендага биргән. Баязитовлар арыш (15 дисәтинә), бодай (4,5), солы (4), тары (2), борай (1,5), карабодай (1,5) һәм борчак чәчкән. Хуҗалыкларында 4 эш аты, 5 сыер, 30 сарык һәм 5 кәҗә асраганнар. Көндәлек эшләрне 2 ир-ат хезмәтче башкарган. Кыр эшләре вакытында басуларында көнлекчеләр дә бил бөккән.

Лавка тотучыларның калганнары – Бөгелмә мещаннары. Болар арасында хуҗалыгының зурлыгы белән Мөхәммәди Искәндәров (40 яшь) аерылып тора. Ул хатыны, 2 улы (15 һәм 9 яшьләрдә) һәм кызы белән яши. Хуҗалыгында 8 эш аты, 8 сыер, 58 сарык һәм 1 кәҗә асрый. Читтән килгән булгач, аның Азнакайда иманасы булмый. Шунлыктан ул иген игү өчен җирне (14,24 дисәтинә) арендага ала. Ел әйләнәсенә сәүдә эше белән мәшгуль булганлыктан, үз хуҗалыгына аның вакыты аз кала. Мондагы эшләрнең күпчелеген хезмәтчесе башкарган, ә инде игеннәр өлгергәч, кыр эшләренә ул эшчеләр дә яллый торган булган. Сәүдәгәрнең 10 баш умартасы да була.

Тагын бер сәүдәгәр – Гәрәйша Искәндәров (46 яшь) – ел әйләнәсенә Сәпәйдә сәүдә иткән. Анда аның лавкасы була. Хуҗалыктагы авыр эшләрне 2 улы (25 һәм 19 яшьләрдә) башкарган. Гәрәйша сәүдәгәрнең мал-туары һәм чәчүлекләре аз була.

Лавка тотмыйча, аерым төр сәүдә белән шөгыльләнүчеләр дә бар. Беренче чиратта, икмәк сәүдәсенә тукталып үтик. Азнакайда моның белән шөгыльләнүче – Миргали Әхмәтҗанов (30 яшь). Ул чыгышы буенча Бөгелмә мещаннарыннан. Азнакайда анасы, энесе, хатыны, 2 улы һәм кызы белән яши. Икмәк сәүдәсе белән кыш айларында шөгыльләнгән. Моннан тыш, ул Азнакай земство стансасын тота. Аның атлары (11) почта ташыган, земствоның эрелевақлы чиновникларын йөрткән. Әлбәттә, бу хезмәт өчен ул тиешле хак алган.

Ат кына түгел, Миргали Әхмәтҗановның башка мал-туары да күп була. Мәсәлән, сыерлары гына 6 баш исәпләнә. Иманә җире булмый, шуңа күрә иген игү өчен ул якын-тирә авыл кешеләреннән барлыгы 9,82 дисәтинә һәм казнадан 13,85 дисәтинә җир арендага ала. Кыш җиткәч, үзеннән арткан икмәкне сатуга алып чыга торган булган.

Миргали бер хезмәтче тоткан, кыр эшләре вакытында 300 көнлекче яллаган. Моннан тыш, берничә айга ялланган 3 эшчесе дә була. Земство стансасына бәйле эшләрне ул Җиһангир Әхмәтҗанов (45 яшь) белән бергә башкарган, ахры. Чөнки икенчесе документта ямчы (ямщик) дип күрсәтелә.

Җиһангирның хуҗалыгы зур түгел, шуңа карамастан ул хезмәтче тота. Ям чабу хуҗалык эшләре өчен вакытны аз калдырган, күрәсең. Бу вакытта аның өлкән улына 16 яшь кенә була.

Г.Мөхәммәтҗанов (55 яшь) Сәпәй базарында тоз, дегет һәм керосин белән сату иткән. Шаһиәхмәт Рәхмәтуллин (53 яшь) да бу базарга сатарга тоз алып чыккалаган. Моның белән ул кыш айларында гына шөгыльләнә. Аларның икесе дә урта хәлләр рәтендә. Сату өчен кирәк-яракны Бөгелмәдән алып кайтканнар.

Мортаза Исмәгыйлов (40 яшь) йомырка сәүдәсе белән шөгыльләнгән. Ул чыгышы буенча Оренбург губернасы мещаны, хатыны (50) белән яши. Тормышы бай түгел: 2 кәҗә һәм 0,38 дисәтинә чәчүлек.

1897 елгы чыганактан Азнакайда 4 тегермән булуы хакында белдек. Тегермән хуҗаларының икесе (Ибәтуллин, Реутов) турында мәгълүматлар бирик. Мостафа Ибәтуллинга 1900 елда 63 яшь була. Ул хатыны (45 яшь), 3 улы һәм 4 кызы белән яши. Хуҗалыгында 6 эш аты, 7 сыер һәм башка вак-төяк маллар була; барлык чәчүлекләре 20 дисәтинәгә якын. Тегермәндә һәм йортында хезмәтчеләре (2) эшли.

Василий Реутов (43 яшь) авылга Вятка губернасы Алабуга шәһәреннән килә. Ул Азнакай авыл җәмгыятенең бер ташлы тегермәнен арендага ала. Тегермән В. Реутовның үз милке булмый. Гаиләсе – хатыны (36), 4 улы, 3 кызы. Ул 6 эш аты, 6 сыер һ.б. мал-туар асрый. Чит авыл кешеләреннән һәм казнадан арендага алган 15,63 дисәтинә җирдә иген игә, бер хезмәтче тота.

Азнакайда төрле һөнәр белән шөгыльләнүчеләр күп була. Балта осталарын гына алыйк. Бу һөнәр белән даими шөгыльләнүчеләргә Дәмин Кәримов (67 яшь) һәм аның улы, Тажетдин Гыйлаҗетдинов (65 яшь), Хәмидулла Хәйруллин (45 яшь) һәм Әхмәди Мөхәммәдиев (40 яшь) керә. Калган балта осталарының (Зәйдулла Заһиров, Хәлиулла Фәйзуллин, Гани Хәкимов, Нургали Хөснетдинов, Заһидулла Хәйруллин, Сәгыйдулла Хәйруллин, Солтангәрәй Шәнгәрәев) эш сезоны 2-6 ай тәшкил иткән. Вилдан Хәлиуллин (47 яшь) җәй көне көпчәкләр ясап саткан.

Төбәктән кайбер балта осталары Богырыслан өязенә, Уфа якларына, Чулман һәм Идел буендагы авылларга барып, агач әзерләү эшенә ялланган. Мондыйлар Әсәй һәм Уразай авылларыннан аеруча күп була. Азнакайдан исә бер генә кеше (Сәлим Шәнгәрәев) күрсәтелә.

Статистик әдәбиятта алар хакында шундый юллар бар: «С собой пильщики захватывают только пилу на плечо, подпилок за пояс и крюк, да на первое время немного хлеба в мешок. Работа с ходьбой в общей сложности продолжается не более 2 месяца и в течение этого времени зарабатывают на пару рублей 20 и 10 на человека. Подряжаются пилить с бревна длиною в 8 аршин по 5-6 коп. «с реза», с более короткого бревна 2-3 коп. «с реза». Но как в этом, так и в других промыслях, размер самого промысла и заработка зависят главным образом от урожайности хлебов, так как строительная горячка в селениях настает большею частию после момента уборки хлебов. Случается, что татары исколесив «по стороне» верст 100-200 приносят домой каких-нибудь 4-5 рублей».

Агач кисүчеләрнең югарыда күрсәтелгән хезмәт хаклары зурмы соң? Ул чакта эш аты уртача 25 сум торган. Димәк, мондый ат алу өчен бер кешегә биш айга якын урман кисәргә кирәк. Әле ярый, елы уңышлы булса.

Йон тетү һәм киез итек басу – шулай ук киң таралган һөнәр. Йон тетүчеләрнең (Халикъ Газизов, Харис Узиев) эш сезоны бер-ике айдан артмый. Киез итек басучылар арасында исә бу эш белән 2-3 айдан 8 айга кадәр шөгыльләнүчеләрдән Гатиятулла Гыйззәтуллин, Сәхипгәрәй Шәнгәрәев һәм Шәйхелвәли Гыйльмановларның исемнәре билгеле.

Тегүчеләр – авылда ике кеше. Аларның өлкәне – Хафиз Галимов (40 яшь). Ул ел буена бөтен авылга күлмәк-ыштан һәм башка кием-салым тегә. Икенчесе (Заһидулла Хәбибуллин) исә, тегүчелек белән кыр эшләреннән соң, елга 5-6 ай чамасы шөгыльләнгән.

Бүрек тегү остасы авылда берәү генә. Гыйльман Хәлиуллин (55 яшь) аны бары кыш айларында гына теккән.

Башка һөнәрчеләрдән тимерчеләрне (Әхмәтгәрәй Гәрәев, Котлыкай Гәрәев), чабатачыларны (Аллабирде Габдрахманов, Мөхәммәди Хәмидуллин), мич чыгаручыны (Бәдретдин Габсаттаров) һәм ташчыны (Гали Бадыкшанов) күрсәтергә кирәк. Шулай итеп, 1900 елда авылда күп төрле һөнәр ияләре яши.

Һөнәрчелек – күп кешеләр өчен төп керем чыганагы. Андыйлар аз-маз җирләрен арендага биреп, бөтен вакытларын һөнәрләренә багышлаган. Әмма һөнәрчелек белән кыр эшләреннән соң гына шөгыльләнүчеләр күбрәк. Алар моңа бары өстәмә керем чыганагы итеп кенә караган. Авыл хуҗалыгы эшләренә яллану да – төп яисә өстәмә керем чыганагы. Көнлекче яисә хезмәтче булып ялланучылар арасында җирсезләр дә була, әмма бик аз – берничә генә кеше (берсе урыс милләтеннән).

Зиннәтулла Гайнуллин (48 яшь) һәм Шәнгәрәй Хәбибуллиннар ел буена авылда көнлекчелектә йөргән. Аларның кәҗәдән башка мал-туары булмый. Беренчесенең җире 5 дисәтинәдән арта. Шуның 3,27 дисәтинәсенә иген чәчкән, тагын 2,46 дисәтинәсен парга калдырган. Ш. Хәбибуллинның чәчүлекләре азрак (2,39 дисәтинә). Якын-тирә хуторларга һәм усадьбаларга да көнлекчелеккә йөрүчеләр күзәтелә. Шуларның берсе – Хәйрулла Гайнуллин (40 яшь). Ул көзен бер ай Микулин волостенда алпавыт Елачич имениесендә эшли. Үзенең исә чәчүлек җире аз (1,63 дисәтинә).

Елачичлар – төбәктә бай мал-мөлкәтле алпавытларның берсе. Бөгелмә өязендә иң зур җир биләмәсе аларныкы була. 1866 елда Франц Осипович Елачичның җир биләмәсе 10121 дисәтинә тәшкил итә. Аның Бөгелмәдә һәм Петербургта йортлары була.

Елачичлар турында 1890 елгы мәгълүматларга тукталыйк. Ф.О. Елачич вафат булган, шуңа күрә телгә алынмый. С.К. һәм А.Ф. Елачичлар Бөгелмәдә һәм Микулин волостендагы Павловка авылында ике аракы куу заводы тота. 1897 елда аларның Микулин һәм Сумароково волостьларындагы җир биләмәсе 10275 дисәтинә тәшкил итә. Бөгелмә өязе земство җыелышы шәһәрне Самара-Златоуст тимер юлы белән тоташтыру турында карар кабул иткәч, Петербургта яшәүче статский советник (генерал-майорга тиң) А.Ф. Елачич ярдәм итәргә алына. Бөгелмә өяз управасы йомышы буенча, ул хөкүмәт даирәләрендә бу эш артыннан йөри.

Югарыда телгә алынган Микулин волосте атамасы алпавыт Микулиннарга тоташа. Җир биләмәләренең зурлыгы буенча Микулиннар бары Елачичлардан гына калыша. 1866 елда аларның барлык җирләре 6763 дисәтинә исәпләнә. Өлкән Микулин (Федор Федорович) – коллежский советник (полковникка тиң чин) дәрәҗәсендә йөри, Михаил һәм Дмитрий исемле уллары була. Михаил Микулинның улы Николай 1890 нчы елларда Бөгелмә өяз земствосына гласный итеп сайлангач, шул земствоның Управа әгъзасы булып торуы мәгълүм. Бер үк вакытта Дмитрий Микулинның улы Александр да земствога сайлана. XIX гасыр ахырында аларның Микулино волостенда ике хуторы була. Аларның берсе – 20134 дисәтинә зурлыкта, анда 2 су тегермәне. Микулиннарның өченче биләмәсе (298 дисәтинә) Сумароково волостенда урнашкан.

(Дәвамы киләсе санда).

Таһир КӘРИМОВ,
тарих фәннәре кандидаты.

Чит илдә

Рәссам Әсгать Сәфәргалин 1922 елның 8 августында Татарстанның Актаныш районы Иске Кормаш авылында туган. Былтыр аның тууына 100 ел тулды.

● «Шәфкать туташы». 1965 ел.

Әсгатьнең әти-әнисе инкыйлабка кадәр дә, аннан соң да авыл хуҗалыгы өлкәсендә хезмәт иткән. Ягъни әтисе – 1933 елдан, ә әнисе 1930 елдан башлап гомер буе колхозда эшләгән. Рәссам үз автобиографиясендә шул хакта аныклаган, һәм әтисенең – 1952 елда, 77 яшендә, әнисенең 1962 елда, 84 яшендә вафат булуларын да искә алган.

1929 елны Әсгать авылдагы башлангыч мәктәптә укый башлый. VII сыйныфны тәмамлауга, бер ел Юдинода, Казан тимер юлы хезмәтенә караучы ФЗОда белем ала.

1938 елда, 16 яшендә, ул Казан сынлы сәнгать училищесына укырга керә. Коточкыч афәт килеп, Бөек Ватан сугышы башлангач та, IV курстагы егетне Совет Армиясе сафларына мобилизациялиләр. 1942 елда Әсгать Газизулла улы Сталинград фронтының хәрәкәттәге армиясендә телефонист була. 1943 елда аңа Сталиногорск хастаханәсендә дәваланырга туры килә. 1944-1945 елларда Актаныш егете Мәскәү хәрби округына караган полк клубында өлкән рәссам вазыйфаларын үти. 1945 елның ноябрендә демобилизацияләнә һәм Казан сынлы сәнгать училищесында укуын янә дәвам итә. Уку йортын 1947 елда тәмамлый. Шул ук елны Харьковка китеп, андагы Дәүләт сынлы сәнгать институтына укырга керә. Уку белән беррәттән институтның җәмәгать эшләрендә дә катнаша.

Югары уку йортын Ә.Сәфәргалин 1953 елда тәмамлый. Аның, «Икмәк унды» дип аталган диплом эше (141х272см) югары бәяләнә. Картинаны барча диплом эшләрен җыйнап оештырылган II Бөтенсоюз күргәзмәсенә үрнәк итеп тә элеп куялар. Картина, чыннан да, совет чорында иҗат ителгән яхшы әсәрләр рәтенә керә алырлык дәрәҗәдә язылган. 1974 елдагы язмасында рәссам шушы хезмәте хакында: «Завод музеенда, Җиңү сараенда саклана», дип аныклаган.

Яшь белгеч УССР Рәссамнар берлегенең Харьков оешмасында эшли башлый. 1953 елдан башлап бихисап күргәзмәләрдә катнаша. Аның әсәрләрен чит илләрдә узучы күргәзмәләр өчен дә сайлыйлар. Яшь рәссамның 1954 елда язылган «Каникуллар» картинасы Украинаның Россиягә кушылуына 300 ел тулу уңаеннан оештырылган күргәзмәгә куела. Аны өлкә мәдәният бүлеге сатып ала. 1957 елда иҗат ителгән «Хат» әсәрен исә, күп кенә дәрәҗәле күргәзмәләрдә күрсәтелгәннән соң, Львов картина галереясында урын ала. Гомумән, бу татар иҗатчысының шактый картиналары УССР Мәдәният министрлыгы тарафыннан сатып алынган.

1954 елда аны Украина Рәссамнар берлегенә кандидат итеп кабул итәләр. Ә 1958 елдан башлап Ә.Сәфәргалин инде СССР Рәссамнар берлеге сафында. Ул әсәрләрен киндерләргә майлы буяулар белән яза, әлеге картиналар совет чоры сәнгатен үз итүче бар тамашачыларның да күңелен яулый. Болар: «Хат» (1957), «Студентлар язы» (1961), «Уңыш» (1963), «Шәфкать туташы» (1965), «Май яңгыры» (1967), «Апрель» (1968), «Хезмәт семестры» (1968), «Егетләр, атларны җигегез» (1969), «Кышкы челтәрләр» (1971), «Язгы сулар» (1971), «Карлыгачлар» (1972) һ.б.

Оста үз автобиографиясендә шул хакта да ассызыклаган: «1963-1971 елларда Украина Рәссамнар берлеге карамагындагы Харьков оешмасында сынлы сәнгать советы рәисе вазыйфаларын башкардым. 1969-1971 елларда яшь рәссамнар белән эшләү комиссиясе рәисе дә булдым. 1971-1973 елларда – Харьковтагы Сынлы сәнгать фонды идарәсе рәисе булып эшләдем. 1965 елдан алып – УССР Рәссамнар берлегенең Харьков оешмасы идарәсе әгъзасы, ә 1968 елдан алып – УССР Рәссамнар берлегенең республика идарәсе әгъзасы, 1971 елдан башлап исә Харьковтагы оешмабызның президиум әгъзасы һәм идарә рәисе урынбасары булдым». Моңа өстәп, шушы республика берлегенең III, IV һәм V съездларында, СССР рәссамнарының Бөтенсоюз съездларында да абруйлы рәссамның делегат булып катнашуын искәртик, әлеге республика иҗатчылары аны, олы талантына күрә, бик тә ихтирам итә. Ә.Сәфәргалинга 1965 елда совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңеп чыгуына 20 ел тулу уңаеннан оештырылган «Тынычлык сагында» Бөтенсоюз сынлы сәнгать күргәзмәсендә экспозицияләнгән «Шәфкать туташы» өчен – СССР Рәссамнар берлеге дипломын, 1967 елда «Хат» әсәре



● «Җир чәчәк ата». 1974 ел.



● «Кышкы челтәрләр». 1971 ел.

дан алган рәссам

● «Хат». 1957 ел.



● «Май яңгыры». 1967 ел.

өчен – СССР Рәссамнар берлеге грамотасын һәм 1968 елда УССР Югары Советы Президиумы грамотасын тапшырганнар. 1970 елда иҗатчы «Шәфкать туташы», «Хезмәт семестры» картиналары өчен Харьков өлкәсенең Советлар Союзы Герое Александр Зубарев исемендәге комсомол премиясенә дә лаек булган.

Ул – «За участие в Великой Отечественной войне», «За Победу над Германией в Великой Отечественной войне» медальләре, «Двадцать лет Победы в Великой Отечественной войне», «50 лет Вооруженных Сил СССР», «За доблестный труд. В ознаменование 100-летия со дня рождения В.И.Ленина» юбилей медальләре белән бүләкләнгән шәхес.

Әсгать Газизулла улының үз күргәзмәләре нибары 1954 һәм 1977 елларда Харьков каласында гына узган. Бу жанрлы әсәрләр остасы, тыйнак, көр күңелле, тырыш зат 1971 елда гына УССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән дәрәҗәле исемгә лаек булган.

1973 елда УССР Рәссамнар берлеге аны А.И.Куинджи исемендәге мемориалның истәлек медале белән бүләкләгән. Милләттәшебез Т.Г.Шевченко исемендәге премиягә дә ике тапкыр тәкъдим ителгән. Әлбәттә, бу дәрәҗәләр артында әлеге талант иясенең гаять хезмәт сөючәнлеге, үз һөнәренә җитди караштa булуы тора. Аның әсәрләре караңгы төсмерле сурәтләр ясауга юнәлдерелмәгән. Әйтик, Бөек Ватан сугышына багышланган «Язгы сулар»ны, «Шәфкать туташы»ын күрүче тамашачылар да күңелләренең ниндидер якты һәм тыныч хисләр белән тулылануларына хакында искәртә. Әлбәттә, сугыш мәхшәрендә катнашкан шәфкать туташлары С.Алексиевич повестенда яу чорын башкача искә ала: «Без җиңүгә ышандык, хәтта чигенгәндә дә. Үзебез хакында уйларга бер минут та вакыт булмады. Күз алдында бары яралылар, яралылар...»

Сәләт иясе 1960-1970 еллардагы социалистик реализм сәнгате рәссамнары арасында киң таралган популяр сюжетка да мөрәҗәгать итмичә калмаган. Әйе, мондый картиналар белән СССРдагы меңләгән Пионерлар йортлары, мәктәп һәм пионер лагерьлары диварлары бизәлде. Сүз – «Ю.Гагарин «Артек»та кунакта» картинасы хакында. Әлеге киндердә Җирнең беренче очучы-космонавты һәрвакыттагыча көләч, игелекле йөзле, гадилеге белән гали, бар планета балалары өчен үрнәк зат итеп сурәтләнгән.

Милләттәшебезнең картиналары Украинаның Милли сынлы сәнгать музеенда, Харьков, Львов, Донецк, Севастополь, Запорожск шәһәрләрендәге дәүләт музейларында саклана. Аның әсәрләре Украина, Италия, Канада, Япония, Германия һ.б. дәүләтләрдәге шәхси тупланмаларны да бизи.

Әсгать Газизулла улы 1954 елда гаилә корган. Аның җәмәгате – Елена Шевченко-Соханева, табибә-бактериолог, Харьков санэпидстанциясендә хезмәт куйган. Гаиләдә 1957 елда – кызлары Надежда, ә 1961 елда уллары Андрей туган. Милләттәшебезнең 1974 елда кулдан язган автобиографиясе шушы мәгълүматлар белән тәмамланган да. Рәссам 1975 елның 26 августында, ни кызганыч, нибары 53 яшендә, Харьковта вафат була.

Автобиография язылган соңгы биткә 1978 елда рәссамның җәмәгате Елена Ивановнаның кыска гына язмасы да өстәлгән, ул: «Без барыбыз да Әсгатьне яратабыз

һәм аның хакында истәлекләрне хәтеребездә саклыйбыз. Безнең өчен ул – һәрчак исән», дип тәмамланган. Болардан тыш Актаныш туган як музеенда иҗатчының күп картиналары атамалары теркәлгән исемлек, аның хакындагы берничә кыска язма да саклана.

Интернетка күз салсак: Надежда Сәфәргалинаның табибә һөнәрен сайлап, 1982 елда Харьков дәүләт медицина институтын тәмамлавын, медицина уку әсбапларын нәшер итүдә автордаш булуын күрәбез. Ә менә рәссамның улы Андрей исә, әтисе һөнәрен сайлап, рәссамлыкка укыган. Андрей Әсгать улы 1983 елда Харьков сынлы сәнгать-сәнәгать институтын тәмамлаган, озак еллар буе концептуаль сәнгать өлкәсендә эшләгән. Ул үз хезмәтләрен ефәккә майлы буяулар белән ясый, рәссамлыкта үз авторлык технологиясен уйлап табучы да. Бөтенукраина, төбәк күргәзмәләрендә катнашкан, аның да эшләре бер дистә дәүләтләрдәге шәхси тупланмаларда саклана.

Кояшлы көннәргә бай августта дөньяга килгән рәссам әсәрләрен якты төсләр кулланып кына язган. Ул сәламәтлекләре ташып торган, тырыш ир-атларны һәм



● «Язгы сулар». 1971 ел.

хатын-кызларны киндердә күңел күтәренкелеге халәтендә генә тасвирланган. Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларның атмосферасын без шушы әсәрләр аша да бик яхшы тоемлыйбыз. Гомумән, бер гасырда туып, шул ук гасырда вафат булучы иҗатчылар башкаларга караганда бәхетлерәктер дә, бәлкем. Чөнки сугыш михнәтләрен күргән әлеге рәссамга XXI гасыр вакыйгаларын алдан сөйләүче табылса, ул аларга ышанмас та иде. Безгә исә аның тынычлык темасына багышлап язылган, киләчәк буыннарга үз теләк-әманәте итеп калдырган яхшы әсәрләренә янә күз төшереп, тынычлык хакына догалар кыласы гына кала...

Әлеге рәссамыбыз язмышы да янә шул хакта раслый: гомер кыска – сәнгать мәңгелек. Әсгать Сәфәргалинның якты дөньядан китүенә – инде 47 ел. Актаныш үзәгендә әлеге талант иясенә бюст та урнаштырылган.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Нәгыйулла Гыйззәтулла улы Хәсәнов – Кытайда туып үскән милләттәшебез. Татарча искиткеч яхшы сөйләшә. Һөнәре буенча – кытай теле укытучысы.

● Нәгыйулла (сулда) этисе Гыйззәтулла, әнисе Хәлимә, энеләре Әсгать һәм Вәлиулла белән.

ЧИН ИЛЕ ТАТАРЫ

– Нәгыйулла, күпләр өчен Кытай – бик ерак җир. Сез мәнә соңгы тапкыр туган якларыгызга кайчан кайта алдыгыз?

– 2019 елның декабрендә кайтып килгән идем, шуннан бирле кайта алганым юк. Әүвәл локдаун башланды, аннан соң да карантинның катгый таләпләре йомшармады. Әйтик, якын туганыбызның улы Казанда белем алып бетергәч, 2021 елда, очкычка утыру өчен, өченче тапкыр билет алгач кына Кытайга кайтып китә алды. Анда килеп төшүгә үк, аны да, башкалар белән бергә, 15 көн карантинга ябып куйдылар. Үз хисабына, билгеле. Аннары Башкалага юл тотты, тагын 15 көнлек карантинга тыктылар. Аннары үз шәһәре янәшәсендә тукталды, анда шулай ук 15 көн карантинда тоттылар. Өй бусагасын атлап кергәч тә, тагын 10 көн беркая чыга алмады, өй карантинында утырырга мәҗбүр булды. Җиңел түгел хәлләр...

– Инде 2021 елда шундый таләпләр саклангач, 2020 елда алар нинди иде соң?

– 2020 елда кешеләрне йортлары белән бикләп, йорт ишегенә мөһерле кәгазь ябыштырып куялар иде. Ул кәгазьне беркем дә ертып урамга чыкмады. Һәр йорттагылар үзләренә кирәк ризык, дарулар хакында исемлек язды, дәүләт структурасы хезмәткәрләре, махсус төркемнәр, шуларны җыеп, ябыштырылган кәгазьне алып, сораган товарларны биреп, яңадан мөһер сугылган кәгазь ябыштырып, бикләп китте.

– Бездә мондый хәл булса, урамга чүплек канализациясе аша төшеп булса да чыгарлар иде, валлаһи...

– Кытайда тәртип көчле, дисциплина нык. 2022 елда да вирус афәтенең янә яңа дулкыны узды бит әле... Әти-әнием, туганнарым җәй айларында тагын озак вакыт – 100 көн каратинда утырды.

– Нәгыйулла, сез балачактан ук татарча шулай камил сөйләшәсезме?

– Әйе, чөнки гаиләбездә татарча гына аралашу кабул ителгән. Безнең нәселнең өченче буыны Кытай дәүләтендә туды, шунда яши. Мин 1983 елда туганмын. Без гаиләдә 3 ир бала үстек: мин, энекәшләрем Әсгать һәм Вәлиулла. Нәселебездә Кытайга сәүдә эшләре буенча барып йөрүчеләр анда беренчеләрдән булып, инкыйлабка кадәр үк, татар хатын-кызлары өчен мәктәп төзеткән. Ул мәктәп бинасы хәзер дә бар, аны беркем дә сүтми, тарихи бина ул. Аның бер бүлмәсен татар җәмгыяте өчен бирделәр. Татарлар шунда бергә җыелышып, үз мәдәни чараларын үткәрә.

Нәселебездәгеләр анда мәчет тә төзеткән. Әниемнең этисен, Фәйзрахман бабамны исән чагында күреп калдым. Ул зур мулла иде. Инкыйлаб купкач, безнең нәселдәгеләрне Кытайдан кире чыгармаганнар, алар шунда калган. Әмма өметләрен Ватан белән бәйләп: «Кайчан да булса туган илгә кире кайтырбыз әле», дип фикер йөрткәннәр, Голҗа каласында төпләнгәннәр. Мин дә шунда тудым. Бу шәһәрдә төрле милләттәге миллионга якын халык яши. Ул Или елгасы ярында урнашкан, Или-Казах автоном өлкәсендәге кала өязе, Кытайның Шәнҗан-Уйгыр автоном районына керә һәм Казахстан белән чиктәш.

Безнең гаилә өчен Казан, гомумән, татар иле һәрвакыт изге җир булып саналды. Дәү этием Фәйзрахман да еш кына: «Мәнә вафат булырмын, шуннан соң мине Татарстанга кайтарып җирләгез!» – ди торган иде. Әтием Гыйззәтулла Әнвәр улы бу хакта һәрвакыт истә тотты. Әтием 40 елдан артык кытай теле укытучысы булып эшләде. Ә әнием Хәлимә баштарак сәүдә өлкәсендә хезмәт куйган булган, аннары, без тугач, үзен бала үстерүгә багышлады. Әти дә шуны теләде.

– Сезнең Татарстанга килү тарихыгыз нинди?

– Минем әти электән үк Татарстанга бара алсагыз, шунда яши алсагыз, яхшы булыр иде, укыгыз, чит илдә дә яхшы һөнәр кирәк, дия килде. 2003 елда, 20 яшемдә, мине Казахстанга, шундагы туганнарыбыз янына чыгарды. Анда эшли башлауга, татар җәмгыятен табып кушылдым, җирле «Сарман» ансамблендә, төрле концертларда җырладым...

Әти-әнигә гомер буе бик рәхмәтлемен! Әйткәнемчә, этием татар телен онытмаска тырышты. Әнием матур җырлый, этием баянда уйный. Әти безгә атнага бер тапкыр татар җырларын мәҗбүри рәвештә җырлата иде. Ә без кечкенә, үзебез яшендәге туганнарыбыз да бар бит әле... Әти кулына баян алгач, төрлебез төрле якка качып бетәбез, тик ул безне барыбер бергә җыя иде дә татарча җырлата башлый. Әгәр дә өйдә энем белән, онытылып китеп, кытайча сөйләшә башласак яисә кытайча җыр сузырга тырышсак, эти шундук кулына... камчы ала да эләгә безгә. Кытайча без урамда гына сөйләшә ала идек. Аның камчысы һәрвакыт түр башында эленеп торды. Шунысы да бар, без укыган чорда мәктәпләрдә укытучылар балаларны камчы белән кыйный ала, бу рөхсәт ителгән иде. Хәзер бу хәл рәсми рәвештә гамәлдән чыгарылды, әмма укыту барыбер шулай ук дәвам итә. Укытучылар хәтеремдә явыз булып истә калган. Берәрсе өй эшен эшләмәсә, яки аңламаса, укытучы тәнәфестә аңа өйрәтә, аңлата да, берүзен бер бүлмәгә бикләп куя, бала өй эшен эшли иде. Ашаганмы ул, ачмы – анысы укытучыны борчымый, өй эше эшләнгән булырга тиеш. Мин үзем җиңел укыдым. Хәтерем бик яхшы. Кытайның борынгы шигырьләрен дә бер укуда ятлый идем. Башка телләргә сәләтем булуын да тиз аңладым.

Әти сүзе – минем өчен канун. Аның киңәшен һәрчак тыңладым, сүзеннән чыгарга курка идек. Хәзер дә шулай, эти-әни фатихасында булу – бик мөһим.

Кытай мәктәпләре 1-6 сыйныфка кадәр – башлангыч, 7-9 сыйныфкача – урта белем, 10-12 сыйныфка кадәр тулы урта мәктәпне тәмамлаучылар төрләренә бүленә. Аннары имтиханнар нәтиҗәсе буенча югары уку йортында бушлай яки түләп уку мөмкинлегенә ия булуың билгеләнә. Бары да баланың үз тырышлыгыннан тора. Әтием миңа: «Кытай педагогика институтының кытай теле факультетына кер», – диде. Шул белгечлекне алдым. Ни гаҗәп, 17 елдан соң мәнә шушы белемемнең кирәге чыкты да.

2005 елда Кытайга Казаннан Бөтендөнья татар конгрессы хезмәткәрләре килде. Алар бездән имтихан алып, Татарстанда бушлай белем алырлык татар яшьләрен сайлап алды. Без, 38 яшь кеше, бирегә укырга килдек. Әтием дә 2005 елда Казанда узган зур тантаналарга делегат булып сайланды, Казанга безнең белән килде. Милләтебез безне бик яхшы каршы алды! Кан тарту бар икән, сиздем. Татарстанның тискәре якларын күрмәдем дә. Бар җирдә татарча сөйләшәләр, татарча киенгәннәр... И, рәхәт булды күңелгә! Казан дәүләт педагогика университетының татар теле факультетында укый башладым. Бик сөендек! Аеруча әтием шатланды. Бу әле мәрхүм бабабызның васыятен үтәргә мөмкинлек тә туды дигән сүз. Аның кабер туфрагын алып кайтып татар җиренә сиптек, машаллаһ!

– Сезнең нәсел шәҗәрәгез төзелгәнме?

– Ул бик төгәл түгел. Татарстанга килгәнче үк, биредәге үз туганнарыбызны эзли башлаган идек. Татарстанга күп хатлар юлладык. Ниһаять, 2000 елларда безнең хатлар кирәкле инсаннарга ирешеп, беренче тапкыр җавап алдык, фотосурәтләр дә килде. Әниебез нәселе Башкортстанның Бакалы районына барып тоташа. Андагы туганнарыбызны эзләп таптык, берничә елдан соң күрештек. Әти ягыннан бабабыз исә: «Без – Хәсәновлар. Казан арты ягыннан», – ди торган булган. Төгәл сорап калынмаган. Татар матбугатына, радиога да мөрәҗәгать иттек-итүен, тарихчылардан да сораштым, нәтиҗә генә булмады, эти ягы туганнарын таба алмадык.

– Энекәшләрегез дә биредәме?

– Энем Әсгать Кытайда – табиб, операцияләр дә ясый. Ә Вәлиулла Татарстанга килеп, Казанда ике югары белем алды. Башта инглиз теле белгечен укыды, аннары – журналистлыкка, быел мәнә өйләнде, Казанда яшәп эшли.

– Нәгыйулла, сез тагын нинди телләрдә яхшы сөйләшәсез?

– Казахча яхшы сөйләшәм. Инглиз, француз телен дә бераз беләм, русчам начаррак, ә мәнә уйгырча сөйләшә башласам, уйгырлар ялгыш сөйләшәсең, ди... Яшь чакта сәфәрләр кыласы килә бит инде ул. Мин романтика белән дус идем... Биредә бер ел хәзерлек курсында белем алдым,

Хәсәновлар гаиләсе.

бер ел татар теле факультетында укыдым һәм аннары француз теле факультетына күчеп белем ала башладым. Әмма II курста укыганда, кытайлылар миңа бик яхшы хезмәт хаклы эш тәкъдим итте (Алар белән очраклы рәвештә генә урамда танышып, сөйләшеп киткән идем). Бик озак уйлангач, укудан китәргә булдым. Бу хакта әтигә әйтергә курыктым. Эш буенча күп калаларга командировкаларга йөрергә туры килде. Башта мине тәрҗемәче буларак, Чиләбегә юлладылар. Аннары Пермьгә, Нижгарга, Новосибирскига... Компания филиаллары директоры булып хезмәт куйдым. Казанда да филиал ачтылар. Ул, яхшы нәтиҗәләр аркасында, хәтта миңа була ачылды. Мин – тырышып хезмәт куючы реалист. 10 ел шушы юнәлештә эшләдем. Соңрак компания эше буенча Мәскәү, Петербургка, Балтыйк буе дәүләтләренә дә барылды. Эш кытай товарларын халыкка тәкъдим итү белән бәйле иде. Эшли башлап, бер ел узгач, әтиәнигә мул итеп акча салдым, укуны өзүем хакында әйттем. Әти ачуланды. Аннары гына Кытайга кайтып килергә өрҗәт иттем.

– Сезнең җәмәгатегез дә татар милләтеннәнме?

– Айгөл белән 2010 елда гаилә кордык. Шул ук елны Кытайда туй иттек, безнең туйга 800 кунак килде.

Казанда берничә мең кытайлы яши бит, аларның барысы да студентлар түгел. Башта алар өчен гел караоке-клуб ачтым. Кытайлар, гомумән, башка милләт вәкилләрсез генә ял итәргә ярата, бергәләп җырлап, күңел ачуга мөкиббәннәр. Турист булып килүче кытайлар өчен Казанда экскурсияләр оештырырга булдым. Борынгы биналарның тарихы үзем өчен дә кызык иде. Дүрт ай буе экскурсоводлыкка укыдым да: «Сертификат имтиханын йә татарча, йә кытайча гына бирәм», – дидем. «Русча начар сөйләшәм, миңа Татарстанда яшәү өчен татар теле бик җитә», – дидем. Шуннан алар кытайча белүче рус кешесен эзләп тапты, кытайча имтихан бирдем. Тик пандемия башланды, бер ел эшсез утырдым. Хәзерге көндә балаларга кытай телен укытам, бу эшемне бик яратам. Белем бирү – минем өчен шатлык, шушы эшкә алынгач, балаларны нык яратуымны аңладым. Әтием бик талантлы укытучы иде бит, әгәр дә аның югарылыгына ирешә алсам, миңа бик җиткән!

Улларыбыз Әмирхан һәм Айтуганга милли тәрбия бирәбез. Моннан 17 ел элек мине Татарстан колач җәеп каршы алган иде. Язмышым Татарстан белән бәйле булуына бик куанам.

– Хәзерге ата-аналар арасында балалары белән бер көн – татарча, икенче көн – русча, өченче көн – чит ил телендә сөйләшүчеләр бар. Сезнең гаиләдә дә шулай түгелме?

– Юк. Баштарак улларыбыздан: «Кытай телен өйрәнәсегез киләме? Кытай теле сезгә кирәкме?» – дип сорадык. Икесе дә: «Кирәкми», – дип җавап бирде. Җавапларын видеога яздырып алдык. Аларны хәзер дә мәҗбүриләмим. Баланың үз теләге булырга тиеш. Аннары, өйдә мин әти генә буласым килә, өйгә кайткач та укытучы булып, кытай теленә өйрәтеп утыру арытыр иде. Әмирхан кытай телен, уку программасы буенча, дәресләрдә өйрәнә, олимпиадаларда җиңүләр яулый. Ул инде 1800-2200 иероглиф белә.

Зур агач тамырсыз була алмый. Тамырлары булмаса, ул үлә. Шуңа күрә без дә улларыбызның татар телен яхшы белүен телибез. Алар туган телне мәктәптә яхшылап өйрәнер, дип фикер йөртмибез. Гаиләбездә гел ана телендә сөйләшәбез. Айгөл дә Лаеш районының Кече Елга авылы кызы бит.

– Нәгыйулла, әти-әниегез бу көннәрдә ни белән шөгыльләнә?

– Алар – лаеклы ялда. Әтигә – 62, әнигә – 61 яшь. Әтием гомере буе дәүләт эшлеклесе булды. Дәүләт хезмәтендә булгач, аның пенсиясе зур. Анда дәүләт хезмәтендәгеләр эшләгән чакта нинди хезмәт хакы алган булса, шул ук күләмдәге пенсия хакы ала. Башкалар исә үз пенсияләрен алдан кайгыртырга мәҗбүр. Дәүләт эшендә булмаганнар эшләгән чакта, пенсия өчен дип, алдан ук үз акчаларын түләп куя, аннары хөкүмәт аны пенсия яшенә җиткәннәрнең үзләренә бераздлап түли башлый. Әниебез, мәсәлән, шундый пенсия ала. Алар белән «Вичат» махсус кушымта аша атнасына 3-4 тапкыр видеоэлемтә аша сөйләшеп, хәл-әхвәлләрен белешеп торабыз.

Әтием бу көннәрдә генә Г.Тукай шигырьләрен кытай теленә тәрҗемә итте! Шагыйрь хакында, аның иҗаты хакында мәкалә язып, Кытай газетасында бастырып та чыгарды. Минем әтием депутат та булып эшләгән иде, ул тик утыра торган зат түгел.

– Сезнең тагын нинди хоббиегез, яраткан шөгелегез бар?

– Мин татар җырларын җырлаудан тыш, төрле уен коралларында уйнарга яратам. Менә өч атна эчендә тальян гармунында уйнарга өйрәндем. Гомумән, эти безне кечкенә чагыбыздан ук төрле уен коралларында уйнарга өйрәтте. Мин гитарада да, пианинода да, аккордеонда да уйный беләм.

Татарча җырларга кушсалар, татар халык җырларын гына җырлар идем. Яшь барган саен, күңелем шуларга тартыла. Тел очында тора бит алар! Истә кала!

– Кытай яшәешен барласак, әлеге илдәге ир-атлар хатын-кызлар саныннан 30 миллионга артыграк булгач, хәйран күп ир-атлар шул сәбәпле гомер буе өйләнә алмый, дип әйтү дөресме?

– Бу чыннан да шулай. Кытай ир-атларының күбесе парсыз кала дисәң дә була. Чөнки урамда танышу да юк диярлек. Алар күп эшли, аз күңел ача дигәндәй, танышу өчен дип музейларга, кафеларга да атлыгып тормый. 27 яшьтә гаилә кору гадәти күренеш булып саналса да, яшьләр үзләре дә әлеге адымны ясарга ашыкмый. Алар тыйнак та, ата-аналар хәзер үз кызларына булачак җәмәгатен кияү базарлары аша сайлый. Анда дистәләгән анкеталар тутырылып куела, тик булачак гаилә башлыгының матди хәле яхшы булу да зур йогынты ясый. Ә бар ир-атлар да бай түгел. Ярлыга чыгарга теләүче аз. Андагы кытай кызлары: «Үз йортың, машинаң бармы? Акчалы эштә эшлисеңме?» – дип турыдан сораштыра. 2005 елга кадәр гаиләдә бер генә бала булырга тиеш, дигән канун бар иде, шуңа күрә гаиләдә ир бала, нәсел дәвамчысы туу яхшырак дип саналу сәбәпле дә, ир-атлар саны артканга күрә дә, инде хәзер ата-аналарга туачак баланың җенесен алдан әйтү дә тыела. 2015 ел статистикасы кытай ир-атлары, хатын-кызлар белән чагыштырганда, 33,66 млн га күбрәк дип раслаган иде. Хәзер инде кытайларга ике бала табу рөхсәт. Ә татарлар өч бала таба ала. Гомумән, андагы аз милләтле халыкка өч бала табу – рөхсәт.

– Хәзерге Кытайда төрки халыкларның, шул исәптән татарларның хәле авырмы? Мөселман динен тотучылар кыерсытыламы?

– Кытайда бар халыкның туксан проценты – кытайлар, ун проценты – илле биш милләт вәкиле. Бүген анда нибары 4000 нән артык кына татар гомер итә. Аларның күбесе Шәнҗан-Уйгыр автоном районында төпләнгән. Гади халык мөселман динен тота, аларны тынычсызлаучылар юк. Шунысы да бар: дәүләт социализм кысаларында, шуңа да карамастан анда мәчетләр ябылган еллар булмаган. Безнең мәчет тә эшләгән. Кытайлар сөйләшкәндә дә: «Татарларны сакларга кирәк!» – ди. Кытай кануннары нигезендә, дин тоту тыелмый. Анда буддизм, христиан динендәгеләр дә яши. Әлбәттә, уйгырлар үз дәүләтләрен төзергә омтыла, ләкин бит бу һич мөмкин була торган вакыйга түгел. Алар яшәгән җирләр – инде бихисап еллар Кытай дәүләте территориясе.

– Кытай теленә әйләнеп кайтсак, Кытайда чыннан да тулы бер җөмләләр саннар белән язылып кына да аңлатыламы?

– Әйе. Бу ысул без мәктәптә укыганда ук кулланыла иде. Мәсәлән, иң мәгълүм сүзләр – «Мин сине яратам» – сан белән 520 дип языла ала. Яисә 5201314 – «Мин сине яратам һәм сине гомерем буе яратачакмын» дигәнне аңлата. «Сине сагынам» – 360. «Сау бул» – 88. «Тизрәк» – 777. Бу төр язылыш хәзер башлыча кәрәзле телефон язмалары өчен кулланышта. 520 санының әйтелеше кытайча «Мин сине яратам» дигән сүзләр әйтелешенә бик охшаш. Берәр кәгазь битенә 520 дип яза идек тә, дәрес барганда, берәр кызның кулына сала идек. Укытучылар барыбер аңламый иде...

– Милли үзенчәлекләр... Кытай белән безнең гореф-гадәтләрдәге, кануннардагы аермалык шактый. Шуңа берничә мисал да китереп үтик әле, Нәгыйулла.

– Әйтик, кыргый табигатьтә нибары 1600 панда яши дигән мәгълүмат бар. 1962 елдан башлап пандаларны аулау катгый тыелган. Әгәр дә берәрсе пандаңы үтерсә, дәүләт кануны буенча, ул кеше зур җинаять кылган булып санала, чөнки Кытайда панда – милли хәзинә. Аларны әле бик күреп тә булмый, пандалар берничә зоопаркта гына яши.

Кытайда саннарга да мәгънә салынган. Мәсәлән, 6 саны – уңыш, 8 саны бәрәкәт мәгънәсенә тиң. Пекиндагы Халыкара Олимпиаданың 8.08.2008 елда, кичке 8 дә башланып китүе дә шуның белән бәйле булды. 4 санының кытайча әйтелеше «үлем» дигән кытай сүзеннән тон буенча гына аерыла, шуңа күрә алар аны өнәми һәм 4 санындагы йортлар да анда күпкә арзангаракка сатыла. Кытайлар бәйрәм бүләген җөп санда бүләк итүне дә үз күрә. Моннан тыш, Кытайда бер кулдагы биш бармак белән гадәттәгечә бишкә кадәр санагач, шул бер кулдагы бармаклар белән 6 дан алып 99 га кадәр ишарә белән санау да бар әле. Мин дә шулай саный алам. Аның тарихы еракка барып тоташа. Дәү әтием Фәйзрахман әйтә иде: «Ике сәүдәгәр очрашса, бер-берсенең киемнәрендәге хәйран киң җиңнәре эченә бер-берсенең кулларын тыгалар да, сатырга теләүчесе кирәкле бәяне ишарә белән генә аңлата, ә алырга теләүчесе риза яки риза булмавын шулай ук кул ишарәсе белән генә әйтә. Тирә-юньдәге халык та берни ишетми. Сәүдәгәрләр бәяләрне үзара килешкәнче шулай ишарәләп кенә сатулашалар».

Гомумән, кытайча тыныш билгеләре язылышы да башка, әйтик, татарча күп нокта билгесе өч ноктадан торса, кытайча ул өч нокта итеп тә, шулай ук алты нокта итеп тә языла, соңгысы кешенең әйтер сүзе тагын да күбрәк булуын аңлата.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

哈布都拉·托海的文学创作艺术和生涯

Авыл үз тарихчысын зурлады...

Яңа ел бәйрәме алдыннан Яңа Чишмә районының Зирекле авылында дәвамлы төзекләндерүдән соң халык иҗаты һәм көнкүреш музее яңадан ачылды. Ул - республикабызда иң үзенчәлекле булган милли музейларның берсе, аның эшли башлавына да 30 ел. Шушы вакыт эчендә музейның җитәкчесе булып Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мидхәт Газыймов эшләде. Мидхәт абый ел башында үзенең 80 яшьлек юбилеен билгеләп үткән иде, әкөз күне бакыйлыкка күчте.

Мидхәт Газыймов үзе җитәкләгән Зирекле авылы музееи республика дәрәҗәсенә күтәрә алды. Биредә дөньяда тиңе булмаган кул эшләре үрнәкләре, милләтнең гасырлар буе сакланган сандык малы тупланган. Мидхәт абый җыйган чиккән сөлге һәм намазлыклар, кашага һәм чигешләр, күкрәкчәләр, чигүле аяк чолгаулары, чулпы һәм калфаклар Казанда гына түгел, Мәскәүдә уздырылган күргәзмәләрдә дә катнашты. Мидхәт ага Зирекле авылы тарихы, аннан чыккан шәхесләр, имамнар, һөнәрчеләр, сугыш корбаннары һәм ветераннар, туган авылының халык авыз иҗаты, бәетләре, мөнәҗәтләре, географик атамалары, гореф-гадәтләре турында документаль китаплар язып калдырды. Ул авылның елъязмачысы иде.

Музей ачылу тантанасында Яңа Чишмә районының башкарма комитеты рәисе, шушы авыл тумасы Ринат Фасахов, авыл имамы Ильяс хәзрәт, Бөтендөнья татар конгрессының татар краеведлары белән эшләү бүлеге җитәкчесе галим Альберт Борһанов, тарихчылар Фәүзия Бәйрәмова, Нурулла Гариф, Әлмәт районыннан Риза Фәхреддин исемендәге музей директоры Диләрә Гыйлманова, республиканың төбәк тарихын өйрәнүчеләр, районлагы татар авылларының музей җитәкчеләре, Мидхәт абыйның гаилә әгъзалары, авыл халкы катнашты. Төбәк тарихын өйрәнүчеләр оешмасы Зирекле авылы музеена М.Газыймов исемен бирү тәкъдиме белән район җитәкчелегенә мөрәҗәгать иткән иде. Бу җыенда музей диварындагы М.Газыймов исеме язылган элмә тактаны ачу тантанасы да булды.

Инде Мидхәт абыйның үзе турында да китап чыгарыр вакыт җитте. Музейның хәзерге җитәкчесе Лидия Лотфуллина әйтүенчә, булачак китап өчен материал туплана башланган. Мидхәт абыйның кызы Алсу да әтисе турында китап өчен килгән кунаклардан истәлек язмалары сорады. Халык бу очрашудан рухланып таралды, тарихыбызны, рухи мирасыбызны сакларга кирәклегенә инанды.

«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге.

Баш

Иң яхшы көлү – үзеңнән көлү
Халык әйтеме

Безгә ясле-бакчаларга йөрү эләкмәде. Әнкәйләрнең итәкләреннән төшкәч тә, без йортка, аннары урамга чыгып, бәбкәләр, бәтиләр, бозаулар, этләр белән дуслашып, бер-беребезнең телләрен, теләкләрен аңлашып, алар белән бергә табигатьнең бертигез балалары булып яши башладык. Кырларны, урманнарны да зурлардан башка гына айкый идек. Өйгә дә ашыйсы яки йоклыйсы килгәндә генә кайтып кердек. Бервакытны менә шулай чәчәкләр, бөҗәкләр, кош-кортлар, җәнлекләр арасында гамьсез йөгереп йөргән җирдән тотып алып, кулга чүпрәктән теккән букча тоттырдылар да, безне мәктәпкә илтеп бирделәр.

Мәктәптә безнең өчен бөтен нәрсә сәер һәм кызык иде. Парта арасында утыру да, кара такта да, кыңгырау шылтыравы да. Ә иң ошаганы укытучы апабыз булды. Шундый чибәр, яшь, ягымлы! Ул чагында безнең авылда бәдрә чәчле кешеләр аз иде әле. Шуңа күрә, укытучы апаның саргылт бөдрәләрен, аларның елык-елык ялтырап китүләрен дөньяларны онытып карап утыра торган идек. Укытучы апа журнал өстенә иелеп, синең исемең турысына «5»лене куйган чакта шул бөдрәләр, бер-берсенә бәрелеп, чыңлап китәр төсле тоела иде. Беренче «А»ларны дүрт балалы йончыган бер апа укытканга, алар алдында без, беренче «Б»лар, кәперәеп, укытучы апабызның чибәрлеге белән мактанып йөри идек.

Мәктәптә өйрәткән тәртипләрнең иң кызыгы – кул күтәрү булды, һәркемнең һәрвакыт кул күтәрәсе, парта арасында торып басасы килә. Ә кул күтәрергә сәбәп һәрвакыт булып тормый. Шуңа күрә, тышка чыгасым килә дигән сылтау белән кул күтәреп, бер дәрестә классның яртысы «тышка чыгып керә» иде.

Бервакытны укытучы апа безгә: «Класста староста сайларга кирәк, кемне сайлыйбыз?» – диде. «Староста»ның ни нәрсә икәнлеген белмәсәк тә, без дәррәү кул күтәрдек. Минем урыным укытучы өстәле каршында ук.

Урыныммнан яртылаш торып, алга таба үрелеп, кулны укытучының борын төбендә үк җәһәт-җәһәт селкеп торгангамы, апа мине дәште. Торып бастым. «Йә, кемне?» – ди укытучы. Мин назландырып боргаланырга тотындым. «Әйт инде, кемне?» – ди апа. «Мине...» – дим. Укытучы бер мизгел тын торды. Нәни йөрәгем белән сизеп алдым: шомлы иде бу тынлык. Боргаланудан туктап, апага күтәрелеп карадым. Әнә аның иреннәрендә кечкенә генә көлемсерәү эленеп тора. Берәр ялгышлык ычкынды микәнни?! Апа: «Йә, балалар, староста итеп Ләләне сайлыйбызмы?» – дигәч, класс авыр көрсенеп куйды.

Староста булсаң, такта сөртә торган чүпрәкне юешләп керү, укытучылар бүлмәсеннән акбур алып килү кебек эшләр синең үзеңә генә тапшырылачак дип уйлаганбыз, ахрысы. Апа старостаның класстагы тәртипне күзәтү, тәнәфестә кычкырып, сикереп, йөгереп йөрүчеләрне тыю кебек вазыйфаларын аңлаткач, класс җиңел сулап куйды. Мин авыр көрсендем.

Соңыннан белдем инде: староста итеп үзеңне күрсәтмиләр икән. Ул чагында унтугыз яшьтә генә булган укытучыбыз Мәрзия апаның миһербанлылыгын, тактын хәзер дә сокланып искә төшерәм. Әгәр ул шул чагында безгә сайлауның нәрсә икәнлеген аңлатып торган булса, мин иптәшләр алдында бик тә уңайсыз хәлдә калган булыр идем, һәм мин, мөгаен, моннан ары һичкайчан җәмәгать эшләрендә катнашмаска, читтәрәк йөрергә тырышыр идем. Ә бу, үз чиратында, мәктәп өчен зур югалту булыр иде – чөнки мин, старосталыктан соң, җәмәгать эшләренең башка төрләрен дә үтеп, берзаман мәктәп стена газетасының баш редакторы вазыйфасына кадәр үк үсеп җиттем!

Газетаны чыгаруда безгә рәссамыбыз Клим бик зур ярдәм күрсәтә иде. Идея – минеке, рәсем – аныкы. Клим, ясаячак рәсемен күз алдына китереп, карандашын кәгазьгә төрткәнче үк шаркылдап көлә башлый һәм ясап бетергәнче көлүдән туктамый торган малай иде.

● Лена Гайнанова.

Газетаны стенага элгән көнне мәхшәр була. Урамнан килеп кергән һәр укучы аягындагы карын да кагып тормыйча, балалар өелеп торган җиргә килә.

Алда басып торган балаларны этә-төртә, йә иңбашларына тотынып сикерә-сикерә газетаны карарга керешә. Көлеш, кычкырыш. Дәрескә чакырган кыңгырауны да ишетүче юк. Коридорда эрегән кардан су җыела, таеп егылучылар да була.

Бервакытны шундый хәлне мин читтән генә, авызымны ерып, рәхәтләнеп күзәтеп тора идем, алдыма директор абый килеп чыкты. Йөзе бик ачулы. Минем яннан үткәндә: «Учком председателе, комсорг һәм син дәрестән соң минем кабинетка җыелыгыз», – диде.

Бу көннәрдә мәктәптә учком да, комсорг та булмаганга, директор абый янына үземә генә җыелырга туры килде. «Начальникларның башкалары кая?» – ди директор. «Бар булганы монда», – диде кабинетка килеп кергән пионервожатый. – Менә бу кыз элек комсорг иде, аны редактор итеп куйганнан соң, башка комсорг сайларга өлгермәдек әле. Ә учком председателе авырый. Редактор буларак, бу кызны учком председателе урынбасары итеп тә куйган идек». «Һе, бу кызыйдан монарх ясагансыз икән. Бөтен властьне үз кулына алган!» – ди директор абый. Монысы инде артыграк иде. Минем ни гаебем бар монда? Сайламасыннар иде! Мин директор абыйга шулай дидем. Әле болай дип тә өстәдем: «Монарх ул буржуй дигән сүз инде. Мин нишләп буржуй булыйм? Безнең класста Хәлимне дә буржуй дип булмый әле». Директор ихтыярсыз гына сорап куйды: «Ни өчен булмый?» «Чөнки әтисе сугышта үлгән». «Ә ни өчен була?» «Була дип ни... булмый дим ич, ну... буржуйга охшаган гына ул. Класста берүзе кибет кәчтүме киеп йөри. Узган ел Златоустта эшли торган абыйсы калдырып киткән иде. Быел тагын өр-яңа диярлек кышкы пальтосын да калдырган әле!» Минем оста җавабымнан булыр, директор абый көлемсерәде. «Күрәм, син политикада ярыйсы гына сукалыйсың икән, – дигән булды. – Ләкин мәктәпнең дә бит үзенә күрә эчке һәм тышкы политикасы бар. Газетага шулар турында җитди итеп язып булмыймыни соң? Югыйсә, шайтан белсен нәрсә чыгарып эләсез анда. Коридордан үтеп йөрерлек түгел. Укучылар дәрескә соңга кала. Класска кергәч тә әле шул газета турында сөйләшәләр, көлешәләр, үчекләшәләр. Газетагызның кыйбласы юк!»

Директор абый бүлмәсеннән мин борынымны салындырып чыктым. Редактор итеп куйган чакта миңа: «Газета эшен җанландырырга кирәк», – дигәннәр иде. Инде газета да, аны укучылар да җанланды дип куанып торганда гына әрләсеннәр инде үзеңне! Мәктәпнең тышкы политикасы, ди тагын. Анысы нәрсә икән инде? Эчкесе аңлашыла – дәресләр, җәмәгать эшләре, ә тышкысы?..

Гомумән эчке һәм тышкы политиканы да, аларның үзара бәйләнешен дә бераз аңлыйбыз инде аңлавын, анлык кына баш бар. Әйтик, өйдә иелеп идән себергәндә яки физкультура дәресендә мостик ясаганда баш әйләнеп, күз аллары караңгыланып тора икән, ул инде чәйне күбрәк вакыт шул көе генә эчкәнгә. Башка әйбер белән эчәр идең, ул әйберләр илне җимереклектән торгызуга китә. Ә илне Гитлер фашист көчсезләндергән. Шәһәрләрне, авылларны яндырган, кешеләрне үтергән, никадәр баланы ятим калдырган. Шулай итеп, минем чәйне шул көе генә эчүем турыдан-туры Гитлерның басып алу политикасына, фашизмга бәйле булып чыга. Аларын гына беләбез без. Кечерәк чакта гына ул, башта акыл азрак чакта, бүтәнчә уйлыйсың. Әйтик, җәйгә таба, көннәр җылынгач, үзең шикелле балалар белән кырларга, якын урманга чыгып китәсең дә, юа, кузгалак ише үләннәр белән ашказаныңны тутырып,

редактор

өйгә аппетитыңны тагын да ныграк ачып кайтасың, аны япмыйча гына печәнлеккә менеп ятасың... Нәни башыңа төрле уйлар килә: Гөлҗамал әби белән Дәстия әбигә ничә яшь икән? Җитмеш бардыр. Әгәр алар шикелле карт әби булганчы яшәсәң һәм гел ашыйсы килеп торса? Юк, үскәч, бер аппарат уйлап тапмыйча булмас ахыры. Ул, теге, абый калдырып киткән наушниклар кебек башка атландырып куя торган булмас, нәни генә, беләзек шикелле генә булыр. Алдыңда ашарга әйбер булмаса, винтигын «шылт» – сулга борасың да куясың. Бөтенләй ашыйсы килми башлый. Әгәр ашарга әйбер булса, «келт» – уңга борасың. Аша рәхәтләнеп...

«Эләктеме?» – пышылдап диярлек әйтелгән сүзгә сискәнеп киттем. Каршымда мәктәп завхозы Харис абзый басып тора икән: «Диликтырдан, дим, нык эләктеме?» – дип кабатлады ул кабинетка ымлап. «Эләкте», – дим, көрсенеп. Аннары аңа таба омтылып: «Харис абзый, син бит сугышта булган кеше. Медальләрең дә бар. Син эчке һәм тышкы политикаларны да яхшы беләсең инде, әйеме?» – дидем. «Ә как же! Беләм, бик беләм, – диде Харис абзый. – Сугышта без политиканың эчкесен дә, тышкысын да үзебез ясап йөрдек. Сиңа аның кайсысы кирәк?» «Йә, белсәң, әйт алайса, мәктәпнең тышкы политикасы ни була?» – дип, мин абзый алдына сорау куйдым. Харис абзый юк мыегын сыпыргалап торды. Аннары: «Диликтыр үзе үк әйттемени? – дип миңа сораулы карашын текәде. – Диликтыр әйткәченнән... нәрсә булыр дисең? Шул, шкул йортындагы нәрсәләр шәт. Патамушты шкул йорты яныннан Хәйбулла бакчасы башлана. Хәйбуллада нинди политика булсын? Шул, тәгаен, шкул йортындагы нәрсәләр шкулның тышкы политикасы булыр!»

Безнең мәктәп йортында утын сарае, ат абзары, яшелчә бакчасы бар. Нужәли шулар тышкы пролитика булыр? Күңелдә шик барын бар да, тик сугыштан дүрт медаль тагып кайткан Харис абзыйга да ышанмый ярамый...

Ни булса булды, газетаның киләсе санында мондый җитди мәкалә пәйда булды: «Шимбә көнне кич белән Габдулла абзыйның ала кәҗәсе, дүрт бәрәкәен ияртеп, мәктәпнең яшелчә бакчасына кергән һәм ерткычларча кәбестәләргә ташланган. Нәтиҗәдә дүрт кәбестә яртылаш һәлак булган, өч кәбестәнең башы яраланган. 4 нче «А» классыннан ике малай бу эшне үз күзләре белән күреп торган. Ләкин алар, пионер башлары белән, кәҗәдән курыккан һәм аңа бер сүз дә әйтмәгән. Шул аркада мәктәпнең тышкы политикасына зур зыян килгән».

Газетаны кичтән язып, коридорга иртән генә элдек. Безнең класста беренче дәрес – география. Укытучы апа мине карта алып килергә дип укытучылар бүлмәсенә җибәрде. Коридорга чыксам, күрәм, безнең газетаны бер абый укып тора. Менә ул сыны катып көләргә тотынды. Газетадан нинди көлке тапты икән бу? Ачуым чыгып, янына килдем. Гомәр абзыйның Уфада укып йөргән малае икән. «Абый, – дидем, – нигә ул кадәр көләсең? Газетага шүрәле мөгезе төшермәгәннәрдер ич?» Абый миңа карап алды да үз янына дәште: «Кил әле, хәрендәш, кил әле, кара, нәрсә язганнар: Габдулла абзыйның кәҗәсе мәктәпнең тышкы политикасын бозган. Ха-ха-ха... Син белмисеңме, кем язды икән моны? Менә юмор ичмасам, вот юморист! Ха-ха-ха!» Бу тагын шашынып көләргә тотынды. И кыланышы! Әллә кем диярсең, газетадан көлеп маташа. Ә үзе... үзе, бөтен кеше пима киеп йөргәндә, кыланчыкланып, аягына ботинка элгән. Галстук таккан булган. Стиляга! «Туктале, – ди бу, – мин бу мәкаләне үзебезнең институт газетасына бирермен. Мәктәп стена газетасыннан», дип куярмын», – дип, кесәсеннән блокнот, карандаш алып, мәкаләне күчерә дә башлады.

Минем кәефем кырылды. Җитди әйбер турында язсаң да, һаман мәзәк кенә чыгып тора түгелме? Инде хәзер нишләргә? Әллә, мәйтәм...

Уйлавым булды, эшләвем булды. Кич белән избачка киттем. Газета-журналлар актарган булам, алдымда кәгазь, карандаш. Безнең газетага яраклы дип тапкан нәрсәләрне сыптырам гына...

Менә газетаның яңа санын элеп куйдык. Тәнәфестә читтән генә күзәтеп йөрим. Укучылар нишләр икән? Менә бер малай, тыраклап барган җиреннән туктап, газетага кадалды. Берничә секундтан тыраклап үз юлына китеп тә барды. Әнә өч кыз чыркылдашып, серләшеп килә. Газета янында алар да озак юанмады.

Күңелем тынычлангандай булды. Газетаның кыйбласы да әллә кайда түгел, шул избач ягында гына булган икән ич. Избачка ешрак йөри башладым...

Көннәр уза торды, газеталар алмашына торды. Коридорда өелешеп, аяктагы карларны эретеп торучылар да юк, газета аркасында дәрескә соңга калучылар да юк. Редколлегия әгъзаларына үпкә тотучылар да бетте. Югыйсә, элек, газета чыккан саен тәнкыйть өчен «гонорар түләүчеләр» дә булгалый иде. Мәсәлән, бервакытны, физкультура дәресендә Кызыл Ярда чаңгы шуганда, газетада үзен «2»легә атландырып төшергән өчен, Нәүгать мине тау башыннан мин теләмәгән вакыттарак һәм мин теләмәгән яккарак озатты... Дәрескә һаман соңга калып килүе турында шигырь чыгарган өчен, Галимҗан минем әле бүген генә, свежий корымнан изгән карамны мич артына алып кереп түкте... Хәзер рәхәт, газетаны беркем укымый да, беркем үч тә тотмый, директор да ачуланмый. Директор абыйның укучылар газетасы белән танышырга, бәлки, вакыты да булмагандыр инде, әмма аны коридордагы тәртип бик канәгатьләндерә иде бугай, ул кайчагында минем яннан узганда: «Эшләр барамы, баш редактор?» – дип елмаеп киткәли иде.

Менә шулай газета чыгарырга тәмам остарып беткәч, күңелемә бер әрсез уй кереп-чыгып йөри башлады: үсеп җиткәч, әллә, мәйтәм, миннән үтә шәп бер журналист чыгарга итәме?!

Лена ГАЙНАНОВА.

РЕДАКЦИЯДӘН. Газетабызның даими авторы, галимә, текстолог, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Исхакый исемендәге премия, Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты Лена Гайнанова күптән түгел үзенең матур гомер бәйрәмен каршы алды. Аны ихлас котлап, саулык, тыныч тормыш, һич саекмас иҗат көче телибез.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

21 гыйнвар (шимбә). ***Җөмәдел ахир аеның 29 нчы көне. 29 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 9.19 сәгатьтә калка, 15.26 сәгатьтә бата. 23 сәгать 53 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 7.55 сәгать.***

Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек, баш һәм йөрәк зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Арып-талганчы эшләүдән, артык кайнар ризык ашаудан тыелу хәерле.

Ютәлдән дәва

4 өлеш кәбестә согына 1 өлеш шикәр кушып, сүрән утта яртылаш кимегәнче пешерәләр. Көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, 1 әр чәй кашыгы эчәләр. Шикәрле кәбестә суы какырыкны бик әйбәт куптара, тавыш карлыкканны да бетерә.

22 гыйнвар (якшәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 30 нчы көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 9.49 сәгатьтә калка, 17.02 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.59 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

Бәрелеп имгәнгәндә

Чирек стакан кәбестә суына 1 йомырка агы, пычак очына элеп сода кушып, яхшылап болгаталар, марляны шуңа манып, бәрелгән урынга куялар, өстеннән компресс кәгазе, аннары җылы яулык урап, төнгелеккә калдыралар. Иртәнгә кадәр авырту басыла.

23 гыйнвар (дүшәмбе). ***Рәҗәб аеның 1 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 10.08 сәгатьтә калка, 18.41 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.02 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Ревматизм интектерсә

Ревматизмнан дару үләннәре белән генә котылып булмый, әмма хәлне җиңеләйтеп була. 15 грамм әрекмән тамырын 1 стакан суда сүрән утта 15 минут пешерәләр дә, 2-3 атна буе көненә 4 тапкыр, ашар алдыннан, 1 әр аш кашыгы эчәләр. Яки көненә 1 грейпфрут ашыйлар – бу җимештәге биологик актив матдәләр буыннар өчен бик файдалы. Кытайда исә кизил җимеше яки тамыры белән дәвалаunion: 1 чәй кашыгы чималны 1 стакан суда 15 минут пешерәләр дә, 2-3 атна дәвамында көненә 3 тапкыр 2 шәр аш кашыгы эчәләр. Һәр иртәне 1 стакан җылы суга 1 яки ярты лимон согы кушып эчү дә файдалы.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

24 гыйнвар (сишәмбе). ***Рәҗәб аеның 2 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 10.21 сәгатьтә калка, 20.15 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.05 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Татлы дару

Балагыз мәктәптән бик арып кайтамы? Хәлсезлектән зарланамы? 300 әр грамм күрәгә һәм чикләвек, 2 лимонны иттарткычтан чыгарып, 300 грамм бал кушалар, яхшылап болгатып, суыткычта саклыйлар, балага көненә 1 тапкыр 1 чәй кашыгы каптыралар.

25 гыйнвар (чәршәмбе). ***Рәҗәб аеның 3 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,10.31 сәгатьтә калка, 21.45 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.09 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп тупланууын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

26 гыйнвар (пәнҗешәмбе). ***Рәҗәб аеның 4 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 10.40 сәгатьтә калка, 23.14 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.13 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә әти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул, үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

Томаудан дәва

Суганны кыргычта уып, 3 аш кашыгы согын сыгалар, шуңа 1 чәй кашыгы сыек бал, 50 мл су өстиләр. Әйбәтләп болгаталар. Көненә 3 тапкыр берничәшәр тамчысын борынга тамызалар. Суыткычта 3 көн саклана ала.

27 гыйнвар (җомга). ***Рәҗәб аеның 5 нче көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 10.48 сәгатьтә калка, 0.42 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.17 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Бисквит катлама

Камыр өчен 6 йомырка, 6 аш кашыгы (туп-тулы) шикәр оны, 6 аш кашыгы (тулып җитмәгән) он кирәк. Йомырка агын яхшылап туглап күпертеп, шуңа әкренләп йомырка сарысы, шикәр оны, он өстиләр, салмак кына болгаталар. Табага майланган кәгазь җәеп, өстенә бисквит камырын агызалар һәм газ мичендә пешерәләр. Пешеп чыккач, кәгазе белән бергә рулет итеп төрәләр. Суыткач, әкренләп кире җәяләр, кәгазен куптаралар, эчке ягына повидло йә джем, шоколадлы крем йә куертылган сөт сылап, кабат төрәләр. Өстенә шикәр оны сибеп, җиләк-җимешләр белән бизиләр.

Җир йөзендә туган нигез бар

Балтач районының Бөрбаш авылында бик ямьле кичә булды. Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Балтач районы имам-мөхтәсибе, Бөрбаш авылы имам-хатыйбы Җәлил хәзрәт Фазлыев, Казаннан, күрше-тирә районнардан, һәм, әлбәттә, үз төбәгеннән кунаклар чакырып, авылдашларын түргә утыртып, мәдәният йортында «Саклагыз нигез ташын. Бөрбаш авылы тарихы» дигән китапны тәкъдим итү кичәсе уздырды.

Билгеле, мәшһүр хәзрәтнең теләге, көч-куәте белән генә мондый зур чараны оештырып булмый. Әмма ул башлап йөрмәсә, Бөрбаш тарихын кулга алып, мактанасы килә, дип авылдашларын ашыктырып тормаса, мондый затлы китап дөньяга тиз генә килә алмас иде. Хәзер һәр бөрбашлы, затлы тарихыбыз бар, дип горурлана ала. Хикмәт китапның затлы кәгазьдә бер мең данә басылуында гына түгел. Сүз уңаеннан: 608 битле әлеге хезмәтне язу, нәшер итү чыгымнары 2 миллион сумга төшкән. Аның шактый зур өлешен Казанда яшәүче авылдашлары Нияз Галимуллин үз өстенә алган.

Туган авылым урамын...

Әлеге хезмәтнең мөхәррире, туплаучысы, шушы авыл кызы Лилия Нурмөхәммәтованың сөйләвенә караганда, бу җаваплы эшкә бөрбашлылар байтак вакыт элек тотынган. 2008 елда мәктәп директоры Тәнвир Галимов тәкъдиме белән авылда яшәгән кешеләр турында мәгълүмат тупланган. Нигезләр тарихын барлауда Бөрбаш урта мәктәбе укытучылары һәм укучылары, авыл халкы катнашкан. Гасыр башында яшәгән кешеләр турында яхшы хәтерле Хәлимә апа Галимова шактый күпне сөйләгән. 2022 елда, китапны нәшер итәр алдыннан, нигезләр тарихы кабат тулыландырылган. Бу эштә Динә Бәзегетинова (Мөхәммәтгали Яббаров урамы), Рәсилә Мифтахова (Яшьләр урамы), Альмира Мифтахова (Зариф Хафизов урамы), Гөлнур Гыйльметдинова (Пионер урамы), Рәзинә Шакирова (Яңа һәм Васил Гарифуллин урамнары), Әнүсә һәм Гөлназ Галимуллиналар (Фәхретдин Баһаветдинов урамы), Гөлүсә Хәйретдинова (Фидаил Шакиров урамы) ярдәм иткән. Игътибар иттегезме: бөрбашлылар авылдагы тугыз урамның бишесенә күренекле авылдашларының исемен кушкан. Әйтергә оят: күп авылларыбызда урам исемнәре «Колхоз», «Кооператив» кебек атамалардан гыйбарәт. Әле үзебезчә, татарча булган сурәттә дә күпләребез «Үзәк», «Елга буе», «Яшьләр»дән ерак китә алмый. Югыйсә, һәр авылның мактанырлык, горурлыгы булырлык кешеләре бар. Нигә шуларның исемнәрен мәңгеләштермибез?! Билгеле, урамнарыбызга Тукай, Җәлил исемнәре бирү дә хуплауга лаек. Әмма алар белән генә чикләнү дөрес булмас. Гомум милләт күгендә якты йолдыз булып кабынган Муса Бигиев, Садри Максуди, Бакый Урманче, Зифа Басыйрова, Бәшир Рәмиев кебек мәшһүрләребез дә күп ич. Сүз уңаеннан, берничә көн элек Чуаштандагы Комсомол районының Урмай авылында булып кайттым. Анда яңарак кына пәйда булган урамнарына – шактый озак еллар Чуаштан Республикасы Татар милли-мәдәни мөхтәрияте рәисе вазыйфасын башкарган, «Мишәр» фольклор ансамблен җитәкләгән, күптән түгел генә вафат булган авылдашлары Фәрит Гыйбатдинов исемен һәм милли бәйрәмебез уздырыла торган мәйданга якын булганына «Сабан туй» атамасын кушарга җыеналар. Менә һәрберебез иярерлек, матур үрнәк!

Авыл тарихын чагылдырган әлеге китапка бу изге эшкә шактый еллар элек керешкән, авыл тарихын барлауга зур өлеш керткән авылдашлары Габделхак хәзрәт Садыйков, Шәйдулла Фазлыев язып калдырган кулъязмалар, Балтач тарафының күренекле мәгърифәтчесе Гарифҗан Мөхәммәтшинның эзләнү нәтиҗәләре, Фәридә Шакирова кебек шушы авылда туып үсеп хәзер район үзәгендә, шул исәптән тирә-яктагы шәһәр-районнарда яшәүчеләрнең хатирәләре дә күркәм генә кереп утырган.

Бөрбаш – бәхетле авыл. Үз заманында аның тарихы белән мәшһүребез Шиһабетдин Мәрҗани дә кызыксынган (ул әнисе ягыннан бөрбашлылар шәҗәрәсенә килеп тоташа икән). Замандаш, өлкән галимнәребездән Марсель Әхмәтҗанов, Фәйзелхак Ислаевларның хезмәтләрендә дә әлеге авыл тарихына бәйле, кызыклы күзәтүләр бар. Бүген җиң сызганып эшләүче галимнәрдән Ирек Һадиев белән Раиф Мәрданов, китапта күренгәнчә, тагын да тирәнрәк «казынган». Әлеге тикшеренү нәтиҗәләре, күп дәлилләргә, тарихи документларга нигезләнеп, әлеге хезмәткә дә кертелгән. Хезмәт белән танышып чыкканнан соң, Бөрбаштагы кайбер гаиләләрнең утыздан артык буыны ачыклану үз авыллары тарихын язарга алынучыларда соклану катыш көнләшү хисе уятмый калмаячак. 1675 елда вафат булган Көчек улы Туктаргалинең авыл зиратындагы кабер ташын гүя тарих үзе бүгенге көнгә кадәр матди дәлил итеп саклаган. Хәер, авыл үзе заманында нигез салучы әлеге кешенең исеме белән – Көчек Пучинкәсе дип аталган. «Әлеге Көчек нәселе мәшһүр Кара бәк ыруына тоташа. Идегәй шәҗәрәсеннән кала аеруча киң таралган, шактый яхшы ачыкланган нәселләрнең берсе бу», – дип сөйләде бу уңайдан тәкъдим итү кичәсендә Нократ татарлары, Арча кенәзләре тарихын байтак еллар өйрәнгән тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков. Галим, әлеге хезмәтне авылда тәкъдим итү белән генә чикләнмичә, Казанда, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты бинасында да, башкортлар әйтмешли, китап туе уздырырга чакырды.

Алты нәселгә кереп бетә

– Бөрбаш авылы халкы, нигездә, алты нәселгә кереп бетә. Иң күбе авылга нигез салган Көчек бабай нәселенә керә. Авылга нигез салучы шушы кешегә барып тоташучы 83 хуҗалык бар. Тагын икенче бер зур нәсел – Биктимер. Бу нәселгә 41 хуҗалык карый. Гадәттә нәсел линиясе эти ягыннан бара. Әни ягы белән дә карыйсың икән, безнең бөтен авыл диярлек Көчек нәселенә барып тоташа, – дип сөйләде үз чиратында тантананы алып баручы Җәлил хәзрәт Фазлыев.

Тарихтагы риваятьләргә караганда, Туктаргалинең бабасы, ягъни Көчекнең әтисе Типәчне удмуртларга бәйләп караучылар да юк түгел. Әлеге җәһәттән: «Удмурт галимнәренең, Арча ягындагы удмуртлар, янәсе, элек мөселманлашкан һәм татарлашкан, үзләренең хакимнәре булган, диюләре – буш сүз. Бу мәсьәлә белән мавыгып, алар үз ялганнарына үзләре ышанып бетә. Хәтта хәзерге татар галимнәре дә кайчак шул алдавычка эләккәли. Гомумән, татар тарихын төрле яклап йолыккалау күзәтелә. Башка халык галимнәренең Арча ягында, имеш – удмуртлар, Балтач һәм Кукмара якларында – чирмешләр, Минзәлә белән Актаныш якларында – башкортлар, Идел елгасының уң ягында яшәгән чуашлар татарлашкан дип, татар тарихын төрле якка тарткалап, үзләштерергә маташулары тупас оятсызлыктан башка берни түгел. Әгәр шулай булса, ул халыкларны татарлаштырырлык йогынты һәм көчкә сәләтле татарлар үзләре кайда яшәгән соң?» – дип алда телгә алган галимнәр – Ирек Һадиев белән Раиф Мәрданов Бөрбаш тарихында урын алган мәкаләләрендә бик урынлы сорау куя.

Әлеге хезмәттә Бөрбашның колхоз, совхоз булып яшәгән еллары, дини, мәдәни тормыш, спорт өлкәсе киң яктыртылган. Колхозлаштыру елларында нахакка рәнҗетелгәннәр дә онытылмаган. Бөек Ватан сугышы елларында «Идел-Урал» легионына язылып, аннан үзебезнең якка чыгып фашистларга каршы көрәшкән бөрбашлылар – Ярулла Галимуллин белән Шаһимөхәммәт Шәрифуллиннарның ачы язмышларын сурәтләгән сәхифәләрне тетрәнмичә уку мөмкин түгел. «825 нче батальонда булып, партизаннар ягына күчкән әлеге ике авылдашыгызны да геройга тиңли аласыз»– дигән бөрбашлыларга шушы легион тарихын яхшы өйрәнгән тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев.

Озын сүзнең кыскасы, бу китап – авыллары тарихын язарга җыенган бик күпләр өчен яхшы өлге. Әлеге язманы Бөрбаш шагыйрәсе Гөлинә Шәйхинең шигъри юллары белән тәмамлыйк. «Җир йөзендә туган нигез барда ятим була алмый кешелек», – дип яза ул.

Рәшит МИНҺАҖ.

ХИКМӘТЛЕ ВАСЫЯТЬ

Ибраһим Идриснең васыяте һәм онытына язган хаты

Шагыйрь, педагог, нәшир, сәүдәгәр Ибраһим Сөләйман улы Идрис 1857 елның 11 маенда хәзерге Татарстан Республикасы Арча районы Наласа авылында дөньяга килә. 1897 елда ул Казанга күченә һәм көнкүреш товарлары, китаплар белән сату итә. И.Идрис 1907 елда дин галиме Галимҗан Баруди белән берлектә сәүдә йорты оештырып, китап сәүдәсен үстерә. 1908 елда исә үзенең «Милләт» дип аталган нәшриятын ача. Анда 1917 елга кадәр 1,3 миллионнан артык данә белән 256 китап чыккан. Бу китаплар дин, әдәбият, тарих, медицина, гарәп фәлсәфәсе һәм башка темаларга багышланган. Алар белән беррәттән календарьлар, төрле каталоглар да басыла.

И.Идрис җәдидчелеккә, педагогикага караган мәсьәләләр белән бик кызыксына. Иҗатының тәүге җимешләреннән берсе буларак, 1900 елда М.Чиркова варислары басмаханәсендә И.Идриснең «Тәрбияле ата» исемле хезмәте дөнья күрә. 1905 елда И.Н. Харитонов басмаханәсендә бу китап байтак тулыландырылып һәм өлешчә үзгәртелеп, «Тәрбияле ата яки кыйраәт төрки» исеме белән кабат басыла. Әлеге китапның өченче һәм дүртенче басмалары да мәгълүм, дүртенчесе «Тәрбияле ата яки тормыш дәресе» дип аталган һәм ул 1900 елгы китаптан күләмлерәк һәм шактый аерыла.

И.Идрис педагог кына түгел, шагыйрь буларак та билгеле. Аның 1914 елда «Кыз балаларга нәсыйхәт» дип аталган шигырьләр җыентыгы дөнья күргән. Анда «Уку», «Ислам дине», «Мәдех», «Пакьлек бәяне», «Сәламәтлек», «Авыруга сабырлык», «Ашамак бәяне» һ.б. әсәрләре урын алган. И.Идрис үз китапларының титул битендә шигъри юллар язып куюны гадәт иткән.

И.Идрис 1944 елның 31 мартында вафат булып, Казанның Яңа татар бистәсе зиратында җирләнә. Үзе исән чагында, ул якыннарына васыятен язып калдырган. Вафатына 6 ел кала, И.Идрис онытына Наил Мөхәммәд улына бер хат язган. Ул вакытта Наил рус милләтеннән булган кызга өйләнмәкче булып йөргән. Бабасының моңа, әлбәттә, эче пошкан һәм аңа телне саклау хакындагы үгет-нәсыйхәтләрдән торган хат юллаган. Әлеге васыять һәм хат башта И.Идриснең туганнарында кадерләп сакланган, соңыннан аларны Татарстан Милли музеена тапшырганнар. Түбәндә укучыларны И.Идриснең васыяте һәм хаты белән таныштырып узабыз.

«Һиҗри 1325 сәнә [ел], 18 сәфәр, сишәмбе көн.

Милади 1927 нче ел, 30 сентябрь.

Васыять язуы

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Лә иләһә илләллаһ, Мухәммәдүр-рәсүлүллаһ.

Мин – Ибраһим Сөләйман улы Идриси – үземнең сәламәтлегем җирендә, акылым камил чагында ошбу васыятемне язам:

Вафатым соңында [вафатымнан соң] көчегез җиткәнчә мәсариф кылып [чыгымнар чыгарып] күмәрсез.

Мөмкин булса, яздырып куйган ташымны каберем өстенә утырып [утыртып] куярсыз.

Язып калдырырлык беркемгә дә бурычым барлыгын белмим. Тормыш дөньясында кемгә булса да бирәчәгем барлыгы беленсә яки берәүгә эш эшләтеп тә, шул кеше «Мин хакымны алып бетермәгән идем» дип хак дәгъва кылса, ризалатырсыз.

Калган милкем булса, варисларым арасында Коръәнне дәстүр [кулланма итеп] тотарсыз.

Мещанский урамда [урамында] 62 нче йортымның барлыгы [барысы] сатылган. Алган кешеләрнең кулында шаһитләр алдында кулымны куеп, биргән язуым булыр. Анда ничек язылган булса, шуңа карап гамәл итәрсез, һич ихтилаф кылышмассыз [каршылыкка кермәссез].

Үземә табигъ булган [ияргән] варисларыма ислам динендә сабит [нык] булырга, динебездә фарыз булган намаз вә [һәм] руза кеби [кебек] олуг рөкеннәрне [нигез булган гыйбадәтләрне] әда кылырга [үтәргә], дин сәмавияне [күктән иңгән динне] ихтирам кылырга чын калебем [күңелем] илә [белән] васыять кылам һәм, туганнарыгыз арасында үпкә вә низаг чыгармый, мәхәббәт вә әлфәт илә яшәвегезне, үлгән атагызны хәер [яхшылык] белән яд итүегезне [искә алуыгызны], Коръән укып, дога кылуыгызны үтенәм. Шулай булсагыз, минем рухым сездән шат вә разый [риза] булыр.

Ибраһим Сөләйман улы Идриси.

Шәмсетдин Хөсәен улы.

Васыйларым [васыятьне тормышка ашыручыларым]: Әхмәд Идрисов, Әхмәтсафа Садыйков, Габделгаллям Сибгатуллин, Габделхәким Сабитов».

«Хат

1938 нче ел (числосы хәтеремдә калмаган) улым Мөхәммәднең улы Наилгә язган хатымның күчермәсе.

Сәлам бәгъдүһ [сәламнән соң]. Улым Наил, син Идрис бабаңның нәселе тарала торган иң мөһим урында торганлыктан, сиңа каратып түбәндәге сүзләремне әйтеп үтәргә үземне бурычлы дип беләм.

Ишетүемә һәм үземнең белеп кайтуыма бинаән [таянып], тиз көннәрдә үзеңә иптәшлеккә чит телдә сөйләшә торган чит милләт кызын алу фикерендә икәнсең.

Үзегез бер-берегезгә ошасагыз, анысына мин бер сүз дә әйтә алмыйм. Ләкин иң ерак бабаларыбыздан сакланып килгән ана телебез турысында [мәсьәләсендә] сак булуыңны үтенәм. Ул кыз сине яраткач, сиңа гомерлек иптәш булмакчы булгач, килен булып йортка төшкәч, безнең телдә сөйләнүне [сөйләшүне] шарт кылуың тиеш булыр. Ул килен булып килү белән барыгыз да үз телебезне куеп, аның теле белән – русча [илә] белән сөйләшә торган булсагыз, бик зур җиңелү белән җиңелү булачак, дип беләм. Чөнки аның теле йортта дәвам итсә, туачак балалар да русча сөйләшәчәк. Бу исә нәселебезнең Польша татарлары кеби [кебек] булуына сәбәп булып, Идрис бабаңның нәселенә җинаять итүче булачаксың. Фамилия үзгәрмәячәк, дип уйлаю хата.

Фамилияләре белән калган борынгы татар кенәзләрен ишетәсең булыр, шуларны хәтереңә ал. Аларның руслардан ни аермасы бар. Сүземнең кыскасы, иптәшеңне өйрәт безнеңчә сөйләшергә, иҗтиһад итсен [тырышсын]. Дәү атаң Ибраһим Идрисов.

Үземнең васыять кәгазем.

Ибраһим».



● Күргәнебезчә, И. Идриснең кабер ташында да үзенең шигыре язылган. «Йөрдем атсыз – талмады аякларым, эшләдем эш – тынмады бармакларым» сүзләре әлеге олы шәхеснең тормыш юлын, эшчәнлеген, иҗатын тулысынча тасвирлап бирә.

Айдар ГАЙНЕТДИНОВ,
филология фәннәре кандидаты.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

20 гыйнвар – Шәрык клубында – «Гөлҗамал» (Н.Исәнбәт). Зур залда – «Тормышмы бу?» (Г.Исхакый).
21 гыйнвар – Зур залда – «Сөясеңме, сөмисеңме...» (Ф.Бүләков). Кече залда – «Көл» (К.Митани).
22 гыйнвар – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
24 гыйнвар – «Исәнме, улым!» (Б.Абдуразzоков).
25 гыйнвар – «Килмешәк» (С.Гаффарова).
26 гыйнвар – «Әтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев).
27 гыйнвар – «Миркәй белән Айсылу» (Н.Исәнбәт).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

20 гыйнвар – «Чулпан» (Ш.Хөсәенов).
22 гыйнвар – «Карурман» (Л.Янсуар, Р.Гарипова).
26, 27 гыйнвар – Премьера. «Идегәй» (Н.Исәнбәт).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

20 гыйнвар – «Рөстәм маҗаралары» (Аталы-уллы Гадел һәм Рөстәм Кутуйлар).
